ҖОМГА
16 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 38 (5838)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫ ҺӘМ ССР СОЮЗЫ СОВНАРКОМЫ КОТЛАВЫ

Совет кинематографиясе работникларына

ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм ССР Союзы Совнаркомы, үзенең XX еллыгын бәйрәм итүче совет кинематографиясе работникларын котлыйлар.

Совет кинематографиясенең 20 ел яшәве вактында шактый зур уңышларга ирешелде. Совет киносы зур идея-художество көче булып үсте һәм массаны коммунистик тәрбияләүнең куәтле средствосы булып әверелде.

ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм ССР Союзы Совнаркомы киноработникларны иң әһәмиятле һәм иң массовый искусствоны—киноны үстерергә һәм алга алып барырга, илебезгә югары художестволы һәм хезмәт ияләренең культура дәрәҗәсен һәр яклап күтәрү өчен кирәк булган башка картиналарны, СССР халыкларының тарихи үткәннәрен һәм социализм эпохасын ачык чагылдыра торган, совет кешеләренең уңышларын һәм героик батырлыкларын данлыклый торган, төзелешебездәге кыенлыкларны җиңүгә һәм коммунизмның тантанасы өчен киләчәктә дә чын күңелдән көрәшергә халкыбызны туплый торган картиналар бирергә чакыра.

ВКП(б) Үзәк Комитеты. ССР Союзы Совнаркомы.

Җирле Советларның эшендә яңа этап

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына яшрен тавыш бирү тәртибендә гомуми, тигез һәм туры сайлау хокукы принципы буенча беренче буларак үткәрелгән сайлаулар безнең илебездә дәүләт власте органнарының барсын да Сталин Конституциясе нигезендә үзгәртеп коруны тәгәлләделәр. Дәүләтне идарә итүгә хезмәт ияләренең яңа катлаулары күтәрелде. Эшчеләр сыйнфы диктатурасы тагын да куәтлерәк булып әверелде, ул, диктатура, эшчеләр сыйнфының җәмгыяткә җитәкчелегенең тагын да куәтлерәк системасына әйләнделәр.

Сталин Конституциясе җирле Советларның әһәмиятен яңа югарылыкка күтәрде һәм аларга тагын да киңрәк хокуклар бирде. Алар, дәүләт властеның тулы хокуклы органнары, безнең шәһәрләребезнең һәм авылларыбызның чын хуҗалары буларак, үз территорияләрендә культура-политик һәм хуҗалык төзелешенә, үзләренә буйсынган органнарның эшенә җитәкчелек итәргә, илнең оборона сәләтен көчәйтүгә булышлык итәргә, дәүләт тәртибен саклауны, законнарның үтәлүен һәм гражданнарның хокуклары саклануны тәэмин итәргә чакырылганнар.

Җирле Советлар алдында торган бурычлар зур, катлаулы һәм җаваплы. Бу бурычлар турында хезмәт ияләре депутатларының район, шәһәр һәм поселкы Советларының башкарма комитетлары председательләренең һәм секретарьларының республика киңәшмәсендә бөтен тулылыгы белән күрсәтелде.

— Хезмәт ияләре депутатларының Советлары алдында,—ди докладчы, Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы председателе иптәш Тынчеров,—зур һәм җаваплы эш тора. Аларга күп төрле һәм катлаулы хуҗалык ышанып тапшырылган. Халык сайланучысы дигән бөек исемне, сайлаучылар тарафыннан күрсәтелгән бөек ышанычны аклау өчен депутатлар, бөтен көчләрен куеп эшләргә тиешләр.

Сайлаучылар үзләренең җирле Советларына горурланып карыйлар, аларның эшен зур кызыксыну һәм игтибар белән күзәтеп баралар. Халык ышанычын намус белән акларга, үзеңнең шәһәреңне, авылыңны, поселкыңны яратырга, аларның һәр вакытта да алдынгы сафларда булуы өчен, данын арттыру өчен үз-үзеңне аямыйча көрәшергә—һәрбер советның, һәрбер депутатның намус эше әнә шул.

Сталин Конституциясе нигезендә сайланган советларыбыз үзләренең эшләрен иң гүзәл бер вакытта башлап җибәрделәр. Ленин—Сталин партиясе тарафыннан җитәкләнүче илебез үсешенең яңа полосасына—сыйныфсыз социалистик җәмгыят төзелешен тәгәлләү һәм теземле рәвештә социализмнан коммунизмга күчү полосасына керде. „Хәзер безнең дәүләтнең ил эчендә төп бурычы—хуҗалык-оештыру һәм культура-тәрбия буенча тыныч эштән гыйбарәт“. (Сталин).

Җирле Советлар эшенең эчтәлеге бөтенләе белән һәм тулысынча иптәш Сталинның ВКП(б) ның XVIII нче съездында ясаган докладында һәм съезд карарларында куелган бурычлар белән билгеләнә. Советлар Сталинчыл өченче бишьеллыкның җиңүе өчен, социалистик промышленностьның, транспортның, авыл хуҗалыгының яңа күтәрелеше, культураның тагын да чәчәк атуы, хезмәт ияләренең материаль-көнкүреш шартларын тагын да яхшырту өчен армый-талмый эшләргә тиешләр.

Орденлы республикабыз данлыклы тарихи дата алдында тора. Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүенә быел 20 ел тула. Җирле Советлар бу гүзәл датаны лаеклы рәвештә каршылауга хәзерлекнең башында торырга, хезмәт ияләрен культура-политик һәм хуҗалык төзелеше өлкәләрендә торган конкрет бурычларны үтәүгә тупларга тиеш.

Социалистик революциянең даһи юлбашчылары, бөек Совет дәүләтенең оештыручылары Ленин һәм Сталин инициативасы белән төзелгән республикабыз, бөтен илебез белән берлектә, коммунизм өчен көрәшнең һәм җиңүләрнең данлыклы юлын үтте. Героик көрәшнең һәм җиңүләрнең үтелгән юлы нәтиҗәсендә республикабызның хезмәт ияләре большевиклар партиясе җитәкчелегендә, даһи юлбашчыбыз иптәш Сталин җитәкчелегендә, бөек рус халкының туганнарча ярдәме белән, тарихи әһәмияте гаять зур булган җиңүләргә ирештеләр. Элек царизмның ярым колониясе булган Казан губернасы Совет власте елларында, бигрәк тә Сталинчыл бишьеллыклар елларында танымаслык булып үзгәрде. Сталин Конституциясе кояшы астында экономикасы, культурасы һәм иҗад көчләре чәчәк аткан совет Татарстанының башкаласы Казан индустриаль, фәнни һәм культура үзәге булып әверелде. Промышленность, авыл хуҗалыгы һәм культура төзелеше өлкәләрендә казанылган уңышларыбызны яулап алуда җирле Советларыбыз соңгы урында булмадылар, киресенчә, алар партиябезнең генераль линиясен үткәрүчеләр сыйфатында зур роль уйнадылар.

Совет властеның, аның барлык органнарының көче—массалар белән, сайлаучылар белән нык һәм даими элемтәдә булуда. Аңлашыла ки, хезмәт ияләре депутатларының җирле Советлары үзләренә йөкләнгән зур, катлаулы, җаваплы һәм мактаулы бурычларны үзләренең сайлаучылары белән элемтәне даими рәвештә ныгытканда гына, көндәлек практик эшкә күп санлы активны тарткан вакытта гына уңышлы рәвештә башкара алалар. Киң масса белән элемтәне һәр вакыт ныгытырга, аларның тавышына колак салырга, ихтыяҗларын аңлый һәм канәгатьләндерә белергә, массага җитәкчелек итәргә генә түгел, бәлки, үзеңнең эшеңне үрнәк рәвештә оештыру һәм алып бару өчен, аларның гаять зур эш тәҗрибәсеннән файдалана белергә дә кирәк.

Коммунистларның һәм партиясезләрнең җиңелмәслек Сталинчыл блогының яңа гүзәл тантанасы белән тәгәлләнгән сайлаулар нәтиҗәсендә, совет активының сафларына меңнәрчә һәм ун меңнәрчә яңа кешеләр—талантлы оештыручылар, агитаторлар һәм беседачылар өстәлде. Җирле Советлар бу кешеләрдән дөрес һәм тулы файдаланырга, аларның активлыгын оештыручы һәм иҗад инициативасының башында торучы булырга тиешләр.

Шикләнмәскә мөмкин, хезмәт ияләре депутатларының җирле Советлары, сайлаучылар белән нык элемтәдә булганнары хәлдә, үзләренең эшен яңа, югары баскычка күтәрерләр.

Кызыл Армия һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгына карата художник И. Тоидзе эшләгән плакаттан репродукция.
Г. Широков фотосы (ТАСС фото-клишесе).

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

14 нче февральдә фронтта разведчикларның эзләнүләре булды һәм күп кенә районнарда пехота частьләренең һәм артиллериянең җанлы хәрәкәтләре дәвам итте.

Карелия бугазында безнең гаскәрләрнең уңышлы хәрәкәтләре дәвам итә. Дошман, безнең частьләрнең ударларына түзә алмыйча зур югалтулар ясап чигенә. Уңышлы хәрәкәтләр нәтиҗәсендә 14 нче февральдә безнең гаскәрләр дошманның ныгытылган 16 оборона пунктын алдылар, шуларның 8 е тимер-бетоннан ясалган артиллерия корылмалары.

Безнең авиация дошманның гаскәрләренә һәм сугыш объектларына уңышлы сугыш хәрәкәтләре алып барды һәм разведка очышлары ясады.

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

БЕРЛИН, 13 февраль. Информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Гроссенвальдтка якынгына урында немецләр авыр гранатометлардан атып дошманның фортификация корылмаларын җимергәннәр. Рейн фронтының кайбер участкыларында пулеметтан атышу булган.

ПАРИЖ, 14 февраль. Хәбәр итүләренә караганда, кичә көндез Мозельдән көнчыгыштарак дошманның һөҗүме кире кагылган. Бу һөҗүм алдыннан артиллериядән һәм минометтан атып хәзерлек алып барылган булган. Төнлә артиллериянең җирле хәрәкәтләре генә булган.

НЬЮ-ЙОРК, 14 февраль. Лиссабоннан хәбәр итүләренә караганда, Англиянең „Орегон“ пароходын озатып баручы Англия һәм Франция эсминецлары Германиянең бу пароходка һөҗүм иткән су асты көймәсен батырганнар.

ЛОНДОН, 14 февраль. Германиянең 6.201 тонна авырлыктагы „Вольфсбург“ исемле йөк пароходы Англиянең сугыш карабы тарафыннан эзәрлекләнеп барганда Бразилиянең төньяк яры буенда үз командасы тарафыннан батырылган.

ЛОНДОН, 13 февраль. Соңгы атнада Англиянең барлыгы 19.585 тонна авырлыктагы 3 пароходы һәм нейтраль илләрнең 10.128 тонна авырлыктагы 3 пароходы батырылган. (ТАСС).

ФРАНЦИЯ КОМПАРТИЯСЕ КӨРӘШНЕ ДӘВАМ ИТТЕРӘ

ПАРИЖ, 14 февраль. (ТАСС). Монда, 13 нче округта „Коммунистик оешманы яңадан торгызуда“ гаепләнеп 18 коммунист кулга алынды. Алар барсы да хәрби властьлар карамагына тапшырылдылар. Шуның өстенә сугышка каршы листовкалар саклаган һәм тараткан өчен 5 кеше кулга алынды. Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, полиция кулга алынган коммунисткаларның берсенең квартирасыннан хәзерге вакытта яшрен рәвештә чыга торган „Юманите“ газетасының 500 данәсен тапкан.

БРЮССЕЛЬ, 14 февраль. (ТАСС). Полиция террорына да карамастан, Франция компартиясе үзенең көрәшен дәвам иттерә. Бельгиядәге „Травайер“ газетасының язуына караганда, хәзер сугышка каршы листовкалар папирос тартмаларында, почта ящикләре аркылы һәм меңнәрчә башка төрле юллар белән таратылалар. Франциядә чыга торган реакцион „Гренгуар“ газетасы болай дип яза: „Завод һәм фабрикаларда коммунистлар ячейкаларының яңадан эшли башлауларын инкар итү файдасыз. Предприятиеләрдә бик күп яшрен листовкалар һәм әдәбият таратыла“.

ХРОНИКА

Батыр балтыкчыларны бүләкләү турында СССР Верховный Советы Президиумының указы иглан ителде. „Кызыл байрак“ ордены белән бүләкләнүчеләр арасында Лазо, Шишов, аларның сугышчан иптәшләре капитан-лейтенантлардан Смирнов, Безукладников иптәшләр бар. „Кызыл йолдыз“ ордены белән өлкән лейтенант Белов бүләкләнде.

СССР Халык Комиссарлары Советы Н. В. Гоголь памятнигының скульптор Мануйлов тарафыннан кертелгән композициясен раслады. Цилиндрик пьедестальнең түбәнге өлеше әйләнәсенә „Ревизор“ һәм „Үлек җаннар“ геройларын күрсәтә торган скульптура группасы куелган. Памятникны Москвада Киев вокзалы мәйданына куярга уйланыла. Памятникның биеклеге 12 метр чамасы.

Иранның Вашингтондагы илчесе Шайэсте Рузвельтка ышаныч грамоталарын тапшырды. Шулай итеп бу ике ил арасында моннан берничә ел элек өзелгән нормаль дипломатия мөнасәбәтләре яңадан урнаштырылды. 1936 нчы елны Иранның АКШ тагы илчесе ялгыш рәвештә җинаятьче дип каралып кулга алынган иде. Шуңа үпкәләп, Иран хөкүмәте аны ул вакытта Вашингтоннан чакыртып алган иде.

Болгария телеграф агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Болгариянең баш министре Киоссейванов һәм СССР ның Болгариядәге тулы хокуклы илчесе Лаврентьев сәүдә һәм навигация турында шушы елның 5 нче январенда Москвада кул куелган Болгария—Совет договоры турында ратификация грамоталарын алмашканнар.

Чит илләрдә

Германия—Совет хуҗалык килешүе турында „Фелькишер Беобахтер“ газетасы

БЕРЛИН, 14 февраль. (ТАСС). „Фелькишер Беобахтер“ газетасы бүген Совет—Германия хуҗалык килешүенә багышланган баш мәкалә басып чыгарды. Мәкаләдә бу килешүгә кул куюның бергәләп эшләүне киңәйтүе, аны ныгытуы һәм көчәйтүе күрсәтелә. „Сүз сугыш чорында бергәләп эшләү турында гына түгел, бәлки шулай ук сугыш беткәннән соң да бергәләп эшләү турында бара. Сугыш беткәннән соң Германия һәм совет хуҗалыклары өчен аның гаять зур әһәмияте булачак. Германия—Совет хуҗалык килешүе ике илнең дә товар әйләнешенең экономик программасын билгеләргә теләүләренә туры килә. Бу договор—киләчәккә исәп тотылган ныклы, нигезле экономик политиканың ачык чагылышы. Советлар Союзының гаять зур территориясе чималга бай, Германия исә хәзер аңа мохтаҗ һәм һәр вакыт мохтаҗ булачак. Германия үзенең промышленность мөмкинлекләренә туры китереп Советлар Союзына кирәкле товарларны сата ала. Билгеле, шушы нигезгә корылган Германия—Совет товар алмашуы гаять зур оборотка җитә ала. Маглүм ки, Германия—Совет товар алмашуы беренче елда ук инде үткән елдагыга караганда артыграк булачак. Англия блокадасының перспективасызлыгы безнең өчен ачык булып әверелде“.

Германия—Совет хуҗалык килешүе төзелү турында Латвия матбугаты

РИГА, 14 февраль. (ТАСС). Латвия матбугаты Германия белән СССР арасында төзелгән хуҗалык килешүе турында яза. „Брива земе“ газетасы үзенең Берлиндәге хәбәрчесенең шушы килешүгә багышланган зур мәкаләсен урнаштыра. Мәкаләдә, Совет—Германия хуҗалык килешүе Риббентропның һәм Молотовның үткән елны иглан ителгән хатларында әйтелгән карашларына тулысынча җавап бирә дип күрсәтелә. Хуҗалык килешүе—Германиянең һәм Советның бергәләп эш итүенең ачык дәлиле.

„Яунакас зиняс“ газетасы да бу мәсьәлә буенча язды. Газета яңа килешүенең ике ил өчен дә файдалы икәнлеген күрсәтә. Газета илне индустрияләштерү һәм авыл хуҗалыгын механикалаштыру эшендә СССР ның зур уңышларын, шулай ук Совет—Германия тышкы сәүдәсенең гаять зур мөмкинлекләрен күрсәтеп үтә.

АК ФИННӘРГӘ ЯРДӘМ ИТҮГӘ КАРШЫ ХӘРӘКӘТ

КОПЕНҺАГЕН, 13 февраль. (ТАСС). „Арбейдербладет“ газетасының хәбәр итүенә караганда, Копенһагенда Даниянең порт эшчеләре профсоюзы членнарының җыелышы булган. Профсоюз членнары фин ак гвардеецларына—Англия—Франция империалистлары агентларына ярдәм күрсәтүгә каршы протест белдергәннәр, фин халкын һәм аның халык хөкүмәтен чын күңелдән котлаганнар. Советлар Союзына каршы Даниядәге реакцион матбугатның яла ягу кампаниясе алып баруын күрсәтеп, җыелышта катнашучылар хөкүмәттән реакциянең мондый һөҗүмнәрен туктатуны таләп иткәннәр. Җыелышның резолюциясендә Дания профсоюзлары берләшмәсенең реформист җитәкчелегенең профсоюзларны ак Финляндиядәге сугыш промышленностена эшчеләр туплау органнары итеп әверелдерергә маташуларына каршы да протест белдерелә.

ЛОНДОН, 14 февраль. (ТАСС). Лейбористларның түбәнге оешмаларында партия лидерларының политикасыннан зур ризасызлык сизелә, чөнки бу лидерлар Советлар Союзына каршы интервенция хәзерләргә маташалар. Бу яктан алганда лейбористларның көнбатыш Йоркшир оешмасының Шеффильдтә шушы көннәрдә булып үткән округ конференциясе аеруча күренекле. Конференциядә иң күренекле лейборист лидерларның берсе — Герберт Моррисон Европада империалистик сугышны якларга чакырган һәм фин ак гвардеецлары башлыгы Маннергеймны төрлечә мактап сөйләгән. Конференция делегатлары аңа берничә тапкыр дошманлык белдереп, аның речен бүлдереп торганнар. Делегатларның зур күпчелеге — 13 кешедән 11 кеше — лейбористлар партиясе башкарма комитетының политикасына каршы сөйләгән. Бер делегат Моррисоннан: „Лейборист лидерлар капитализмга каршы көрәшне кайчан башларга уйлыйлар?“ дип сораган. Моңа каршы Моррисон: „Без аны көн саен алып барабыз“ дип җавап биргән. Бу җавап залдагы бөтен халыкны көлдергән.

АКШ ТА НЕГРЛАРНЫҢ ХӘЛЕ

НЬЮ-ЙОРК, 15 февраль. Юнайтед Пресс агентлыгының Сноухиллдан (Мэриленд штаты) хәбәр итүенә караганда, шундагы төрмәгә 500 чамасы кеше бәреп кереп, бер негр хатынын һәм аның 14 яшьлек кызын алып чыкканнар да, линчевать итәргә (суд карарыннан башка үтерергә) маташканнар. Полиция бу ике негрны көчкә генә коткарып калган. Полиция белән бу кешеләр арасында бәрелеш булган. Бәрелеш вакытында ике полицейский һәм халыктан берничә кеше яраланган. Бу негрлар бер нәрсәдә дә гаепле булмаганнар һәм төрмәгә туганнарының, имештер, ак фермерны үтерүдә шикле булулары аркасында гына утыртылган булганнар.

Сноухилл районы АКШ ның иң артта калган районнарының берсе. Монда негрлар ярым феодаллык изелүе шартларында яшиләр. Сноухиллда негрларны линчевать итү вакыйгаләре бик еш була.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Наньниннан төньяк-көнчыгышта кытайлар бик каты сугыштан соң японнарны Линьбиньнән куып чыгарганнар. Үзләренең хәбәрләшү юлларыннан аерылган японнар кытайларның оборона линиясен өзәргә маташканнар, ләкин булдыра алмаганнар. Наньнин—Умин шоссе юлында японнар Уминнан 15 километр көньякка таба Шуансзяога чигенгәннәр. Бу секторда сугышлар дәвам итә. Кытайлар Наньниннан төньяктарак Патанны да алганнар.

Хайнань атавында калган кытай гаскәрләре японнарның базаларына һөҗүмнәрен дәвам иттерәләр. „Цзунмэйжибао“ газетасының язуына караганда, соңгы 10 ай эчендә атауда кытайлар белән японнар арасында 186 сугыш булган. Кытай базаларына бомбалар ташлау өчен җибәрелгән өч япон самолеты бәреп төшерелгән. Шулай ук японнарның 20 броневигы һәм 2 танклары юк ителгән.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

1.000 кешелек япон отряды Тунчэннән чыгып, Хубэй провинциясенең көньяк-көнчыгыш өлешендә кытайларның Цзюлин тирәсендәге позицияләренә атака ясаган. Ләкин кытай гаскәрләренең бик яхшы ныгытылган позицияләренә очырап һәм сугышта 300 ләп кешеләрен югалтып, чигенгән.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Суйюан провинциясендә кытайлар япон гаскәрләренең тагын да алга баруларына каршылык күрсәтеп, Уюаннан төньяк-көнбатыштарак Ланшань районында нык урнашканнар. Үткән атна азагында японнар ярдәмче көчләр алып, көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш юнәлешләрдә һөҗүмне дәвам иттерергә маташканнар. Кытай гаскәрләре бик нык каршылык күрсәтәләр.

Башлангыч партоешмаларда отчет-сайлау җыелышлары

ФАКТЛАРНЫ ҺӘМ САННАРНЫ ТЕРКӘП ЧЫГУ

Коммунистлар җыела башлагач Наркомзем бинасының электры кинәт сүнеп китте. Аны төзәтә торгач, җиденче ярты булды. Отчет-сайлау җыелышына килүчеләрне теркәү оештырылмаганлыктан, партбюро секретаре эшен үтәүче иптәш Зверева килүчеләрне исемлек буенча тикшерә башлады. Җыелышка 58 членның 45 се, 28 кандидатның 20 се килгән иде. Соңыннан Строгонов һәм Грачев иптәшләр килеп керделәр.

Иптәш Звереваның партбюроның ел ярымнан артык чор эчендәге эше турында ясаган отчет докладын җыелышны канәгатьләндермәде. Чөнки ул, нигездә, фактларны һәм коры статистика саннарын анализсыз санап чыгудан, урыны-урны белән бюро эше турында үз-үзен кыйнаудан гыйбарәт булып чыкты.

Отчет чоры вактында 11 кандидат ВКП(б) членлыгына күчерелгән, кандидатлыкка 26 кеше кабул ителгән.

— Бу сан күпме, яки азмы? Аңа да иптәш Зверева анализ ясамады.

Ел ярым эчендә учетка 60 коммунист кабул ителгән, 40 коммунист учеттан төшерелгән.

— Бу нормаль хәлме? дигән сорау да җавапсыз калды.

Коммунистларның 26 сы „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ның әле I, II, III бүлекләрен генә өйрәнәләр. Коммунистлар лекцияләргә йөрмиләр.

— Кемнәр укымый, кемнәр йөрми? Бу сорау да табышмак булып калды.

Наркомзем аппаратының ничек итеп яңа баштан корылуы кебек аеруча мөһим мәсьәлә буенча да бюроның хәбәрдарлеге начар. Чөнки ул бу мәсьәлә белән якыннан шөгыльләнмәгән.

Отчет буенча фикер алышуларга катнашучы иптәшләр партбюро эшен каты тәнкыйть астына алып, партоешма һәм наркомат җитәкчелеге практикасында аяныч һәм көлке фактлар турында сөйләделәр.

Иптәш **Прохоров** аппаратны яңа баштан кору буенча зур аңлашылмаулар турында фактлар китерде, яңа баштан кору эше әле формаль яктан да тәмам булмаган. Башта, ул җитәкчелек итә торган агротехника һәм механизация управлениесенең штаты 28 кешедән билгеләнгән, аннан соң аны 15 кә киметкәннәр, хәзер инде 10 га калган... Кем нәрсә эшләргә икәнне кешеләр рәтләп белмиләр. Яшелчә-җимеш управлениесе бетерелгән булган, хәзер ул тагын кирәк булып чыккан.

Иптәш **Никитин**—бюро члены. Ул, коммунистларның һәм белгечләрнең көндәлек эшләреннән партбюроның читтә яшәгәнлеге турында сөйләде. Аппаратны үзгәртеп кору турында мондый бер факт китерде: элекке төзү управлениесеннән алынып яңа төзелгән производство-территориаль управлениеләргә җибәрелгән 7 белгечкә бер ай буена эш бирмәгәннәр. Аптырагач, алар кире үз бүлмәләренә кайтырга мәҗбүр булганнар.

Җыелышның беренче утырышында фикер алышуларга катнашучылардан **Жуков, Яушева, Айтуганов, Привалов** иптәшләр дә партбюроның кешеләрне белмәве, партия-тәрбия эшләренең торышы начар булуы аркасында аппаратның эше тирән өзеклектә калуы, авыл хуҗалыгының сугышчан штабы ролен башкара алмавы, аппаратта работникларның бик еш алмашынып торулары (кадрлар хәзерләү бүлегендә бер елда биш начальник алмаштырылган) турында сөйләделәр.

Ф. Балыкчы.

ҖЫЕЛЫШЛАР ЗУР АКТИВЛЫК БЕЛӘН ҮТӘ

АПАС, 15 февраль. (ТатТАСС). Бүген Энгельс исемендәге, „Кызыл Армеец“ колхозлары янындагы һәм ВКП(б) райкомы янындагы партоешмаларда отчет-сайлау җыелышлары булып үтте.

Энгельс исемендәге колхоз янындагы партоешма секретаре иптәш Галиәкбәрев җыелышта отчет доклады ясады. Партоешма эшендә яхшы гына уңышлар бар. Отчет чорында оешма җыелышларында барлыгы 98 мәсьәлә каралган, шулардан 56 сы партия тормышы турында.

Оешмада партия җыелышлары яхшы хәзерлек белән үткәрелгән. Колхозда политик-тәрбия эшләре киң җәелгән. Коммунистлар аерым бригадаларга беркетелгәннәр. Оешмада учетта торучы 11 коммунисттан 8 кеше ВКП(б) тарихын түгәрәкләрдә, ә калганнары үзлекләреннән өйрәнәләр. Партия сафларына колхозчылардан һәм тракторчылардан иң алдынгы кешеләр кабул ителгән.

Партоешманың эшендә кимчелекләр дә юк түгел. Бу турыда отчет буенча фикер алышуларда катнашкан иптәшләр күрсәтеп үттеләр.

— Партоешма секретаре поручениеләр бирә,—ди партия кандидаты иптәш Миңнуллин,—ләкин аларның үтәлешен тикшерми. Мин 3 нче бригадага беркетелгән идем. Бригадада җидди кимчелекләр бар. Бу турыда иптәш Галиәкбәревкә әйттем, ләкин ул бригададагы кимчелекләрне бетерү буенча чара күрмәде. Яшь коммунистларны партия эшенә өйрәтүдә җитәрлек ярдәм күрсәтелми.

Җыелыш партоешманың эшен канәгатьләнерлек дип тапты.

Партоешма секретаре итеп Әскәр иптәш Галиәкбәрев сайланды.

Районда партоешмаларның беренче отчет-сайлау җыелышлары зур активлык белән үтте. Коммунистлар партия тормышы мәсьәләләренә аеруча зур игтибар бирәләр.

ЗУР ОЕШКАНЛЫК

15 нче февральдә 2 нче номерлы тегү фабрикасы янындагы башлангыч партоешманың отчет-сайлау җыелышы башланды. Авыру сәбәпле килми калган 5 кешене исәпкә алмаганда, җыелышка барлык коммунистлар да үз вакытында килделәр. Җыелыш билгеләнгән вакытта башланды һәм партоешманың эше турында партбюро секретаре иптәш Ярин доклад ясады.

Башлангыч партоешма ВКП(б) ның XVIII нче съездыннан соң үзенең эшен шактый яхшыртkан. Отчет чоры эчендә ВКП(б) сафына фабриканың стахановчыларыннан һәм инженер-техник работникларыннан 15 член һәм 19 кандидат кабул ителгән. Партия сафына яңа кабул ителгәннәр белән эшләү өлкәсендә дә шактый яхшы нәтиҗәләргә ирешелгән. Политик-масса эшләрен яхшыртуда зур эш башкарылган.

Отчет чоры эчендә цехларда һәм бүлекләрдә 200 дән артык беседа һәм докладлар үткәрелгән. Фабрика күләмендә үткәрелгән беседа һәм лекцияләрнең саны 144 кә җитә. Бу лекция һәм беседаларда 3.122 кеше катнашкан. Политик-масса эшләрен яхшырту нәтиҗәсендә фабрикада 1939 нчы ел планы арттырып үтәлде. Фабрика тегү промышленностеның алдынгы предприятиеләре сафына басты.

Шуны да әйтергә кирәк, партбюро секретаре иптәш Ярин үзенең отчет докладының күп өлешен ирешелгән уңышларга гына кайтарып калдырды. Фабриканың комсомол оешмасында 85 кеше член булып тора. Шулай булуга карамастан, отчет чоры эчендә комсомолецлардан бары тик ике генә кеше ВКП(б) сафына кабул ителгән. Партоешма соңгы вакытта цехларда һәм бүлекләрдә политик-агитация эшләрен йомшарткан. Бу хәл хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына булган сайлаулардан соң бигрәк тә сизелә. Партбюро стена газеталарының эше белән бөтенләй кызыксынмаган. Шуның нәтиҗәсендә күпчелек цехларда стена газеталары кампаниядән-кампаниягә генә чыгарылалар. Иптәш Ярин стена газеталарына партоешманың җитәкчелеге турында үзенең докладында бер сүз дә әйтмәде.

Фикер алышуларда Татаршин, Пунина, Веселов, Галанина һ. б. иптәшләр катнаштылар. Алар барсы да партбюроның эшендә булган уңышлар белән бергә, бик күп җитешсезлекләрне күрсәттеләр. Бигрәк тә ОСО, МОПР, РОКК шикелле ирекле оешмаларның эшенә партбюроның җитәрлек әһәмият бирмәвен әйттеләр. Һәм бу җитешсезлекләрне бетерү өчен конкрет тәкъдимнәр ясадылар.

К. Халиков.

Кимчелекләр читләтеп үтелде

Казан энергокомбинат партоешмасының отчет-сайлау җыелышында партбюро секретаре иптәш Евлампиев, сайлаулардан соң үткән 22 ай вакыттагы эшкә отчет ясады. Бу чорда партоешма состав ягыннан шактый үскән, коммунистларның партия эшендә һәм производствода активлыгы нык кына көчәйгән. 1939 нчы елны комбинатның иң алдынгы кешеләреннән 34 кеше ВКП(б) сафларына кабул ителгән. Практик эштә сыналган коммунистларны һәм партиясез активистларны җитәкче эшләргә күтәрү һәм производствога җитәкчелекне көчәйтү буенча бер кадәр эшләр башкарылган.

Ләкин, докладчы хуҗалык мәсьәләләренә күбрәк тукталып, партиянең эчке эшләренең торышына конкрет анализ ясамады, ул турыда гомумән генә әйтеп үтү белән чикләнде. Партия җыелышы карарларының ничек үтәлүен, цех партоешмаларының эшен, партбюро членнарының эшен тиешенчә күрсәтмәде. Ә партпропаганда, комсомол, профсоюз һәм Осоавиахим оешмаларына җитәкчелек итү мәсьәләләренә секретарь соңыннан гына, ашыгыч кына кагылып үтте.

Фикер алышуларда катнашучы Миңнуллин, Золин, Евтеков, Желобаева, Кудряшев, Гильдеев һәм башка иптәшләр партбюроның аерым коммунистлар белән эшләвенә, аларны большевистик тәрбияләүгә, цех партгруппоргларының эшенә, политик агитация эшенә, эшчеләрнең көнкүреш мәсьәләләренә җидди игтибар итмәвен, күп вакытта кампаниячелеккә бирелеп китүен тәнкыйть иттеләр һәм киләчәктә аларны бетерү өчен практик тәкъдимнәр керттеләр.

Отчет-сайлау җыелышын оештыру ягыннан булган кимчелекләрне дә күрсәтеп үтәргә кирәк. Җыелышка ныклы хәзерлек тәэмин ителмәгән. Җыелыш ярты сәгать соңга калып башланды. Энергокомбинат партоешмасында җыелышларны шулай соңга калып башлау гадәт булып киткән. Дүрт коммунист җыелышка килмәгән иде.

У. Ахметов.

ПАРТБЮРОНЫҢ ЭШЕ КАНӘГАТЬЛӘНЕРЛЕК ТАБЫЛДЫ

Кичә, 15 нче февральдә Әлмәт район башкарма комитеты янындагы партоешмада отчет сайлау җыелышы башланды. Оешманың эше турында доклад ясаучы иптәш Баһаветтинов отчет чоры эчендә партоешманың зур гына уңышларга ирешүен күрсәтеп үтте. Партоешма алдынгы кешеләрдән 11 иптәшне партиягә член итеп, 22 кешене кандидат итеп кабул иткән.

Партоешмадагы барлык коммунистлар да партия поручениеләре алып баралар. Мөхәммәтов, Галиев, Сәлманов иптәшләр агитатор булып эшлиләр. Партия члены иптәш Сафин җитәкчелегендә райисполком работниклары кул пулеметын өйрәнәләр. ВКП(б) тарихының кыскача курсын 11 коммунист үзлекләреннән, 4 коммунист түгәрәктә өйрәнә.

Фикер алышуларда катнашучы коммунистлар партбюроның һәм үзләренең эшләрендәге җитешсезлекларны тәнкыйть иттеләр.

Җыелыш партбюроның эшен канәгатьләнерлек дип тапты.

ОТЧЕТНЫ ЭШЛЕКЛЕ ТИКШЕРӘЛӘР

Язу машиналары заводы партоешмасында отчет-сайлау җыелышы оешкан рәвештә башланды. Җыелышта катнашырга тиеш булган ВКП(б) членнарыннан 27 кеше һәм кандидатлардан 21 кеше җыелышка үз вактында бердәм рәвештә килде.

Партоешма отчет чорында күзгә күренерлек уңышларга ирешкән. 1938 нче һәм 1939 нчы елларда заводта производство планының вактыннан элек арттырып үтәлүен тәэмин итүдә партоешманың роле зур булды. Бу зур казаныш политик тәрбия эшләрен яңача оештыруның, коммунистларны, комсомолецларны һәм, гомумән, завод коллективын алда торган политик-хуҗалык бурычларын уңышлы үтәүгә туплауның нәтиҗәсе булды. Партоешма отчет чорында заводның алдынгылары исәбенә 35 кешегә үскән.

Ләкин уңышлар белән бер рәттән партоешма эшендә җидди генә кимчелекләр барлыгын да әйтергә кирәк. Бу кимчелекләр, барыннан да элек, оешманың акырын үсүеннән, коммунистларның идея, политик белемнәрен күтәрү эшенең йомшак оештырылуыннан, сайлаулар кампаниясендә киң колач алган һәм бай тәҗрибә тупланган массовый-агитация эшенең ныгытылмавыннан, узган елгы уңышлар белән масаю аркасында заводның быел начар эшләвеннән гыйбарәт.

Докладчы иптәш Феоктистов бу мәсьәләләрне үз докладында читләтеп үтте. Ул, югарыда күрсәтелеп үткән җидди кимчелекләрнең сәбәпләрен ачып салмады. Шуңа күрә дә доклад күп кенә коммунистларны канәгатьләндермәде. Доклад буенча фикер алышуларда чыгып сөйләүче иптәшләр отчет докладына күп кенә өстәмәләр кертәләр.

Партоешманың завод алдынгылары исәбенә акырын үсүен аерууча әйтеп үтәргә кирәк. Чыннан да, үз сафында 500 дән артык стахановчы һәм ударник, 106 комсомолец исәпләгән коллективта ике ел эчендә 35 кешенең генә партия сафына тартылуы канәгатьләнерлек түгел. Хатын-кызлардан бары тик алты кеше генә партия сафына алынган. Бу, резерв белән эшләмәүнең ачык мисале.

— ВКП(б) тарихын күп кенә коммунистлар үзлекләреннән өйрәнәләр, ди иптәш Феоктистов. Ләкин бу эшнең оешмада ничек торганлыгы, сыйфат күрсәткечләре турында докладчы үзе дә белми. Күп кенә коммунистлар „кыскача курс“ның 2—3 нче бүлекләрен өйрәнүдән ерак китә алмаганнар. Ә Подсекаева, Ибраһимова, Мөхәммәтҗанова кебек иптәшләр партия тарихын өйрәнүгә бөтенләй керешмәгәннәр.

Велегжанин, Нагорнов, Кушаев һәм башка иптәшләр заводта стахановчылык хәрәкәтенең соңгы вакытларда йомшаруы, күп станокчыларга тиешле эш шартларының тудырылмавы һәм масса сигналларына игтибар бирелеп җиткерелмәве, производствоны рационаллаштыру эшенең үз агымына салынуы турында конкрет фактлар китереп үттеләр.

Ким Баков.

ТАССРның XX еллыгына хәзерлек

РЕСПУБЛИКАНЫҢ XX ЕЛЛЫК ЮБИЛЕЕН ҮТКӘРҮ БУЕНЧА ХӨКҮМӘТ КОМИССИЯСЕНЕҢ УТЫРЫШЫ

15 нче февральдә Татарстан АССР Верховный Советында, Татарстан АССР ның XX еллык юбилеен үткәрүгә хәзерлек буенча Хөкүмәт Комиссиясенең утырышы булды. Аны комиссия председателе иптәш Динмөхәммәтов алып барды. Утырышта Татарстан АССР ның XX еллыгына хәзерлекнең барышы турында Чистай район комиссиясенең (председателе иптәш Жуков), Ленин һәм Киров район комиссияләренең (председательләре Бикбов, Тарасов иптәшләр) докладлары тыңланды.

Фикер алышуларда ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре Матвеев, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы председателе урынбасары Афанасьева һәм Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы председателе Динмөхәммәтов һәм башка иптәшләр катнаштылар.

Фикер алышуда катнашучы иптәшләр Татарстанның XX еллыгына хәзерлек унае белән Ленин һәм Киров район комиссияләренең эшләрендә бераз алга китеш барлыкны сөйләделәр.

Бу комиссияләр үз эшләрен хезмәт ияләре арасында масса-аңлату эшен җәелдерүдән һәм аларны предприятиеләрдә, учреждениеләрдә хезмәт дисциплинасын ныгытуга, производствода хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә туплаудан башлаганнар. Шулай ук районнарны һәм урамнарны төзекләндерү, аларны культуралы төскә китерү буенча хезмәт ияләре арасында шактый эшләр башкарылган.

Татарстанның XX еллыгын каршылауга хәзерлек буенча эшчеләр, хезмәткәрләр һәм интеллигенция арасында социалистик ярыш договорлары төзелгән һәм алар үзләренә конкрет йөкләмәләр алганнар.

Йөкләмәләрне үтәү буенча инде кайбер уңышларга да ирешелгән. Мәсәлән, Казкинохимстройда эшләүче иптәш Ермаков бригадасы январь аенда үзенең планын 236 процент үтәгән. Ленин районында 1.426 укый-яза белмәүчедән 1.199 кеше укуга тартылган, ә Киров районында 884 укый-яза белмәүчедән февраль аенда 74 кеше үзләренең укый-яза белмәүчелекләрен бетереп чыкканнар һ. б.

Комиссия утырышы Татарстанның XX еллыгын үткәрүгә хәзерлек буенча Чистай район комиссиясенең эшлексезлеген күрсәтеп үтте.

Күп кенә күрсәтмәләр һәм директивалар булуга карамастан, бу комиссия шушы көнгә кадәр эшкә чын-чынлап керешмәгән. Чистай районындагы авыл советлары янында Татарстан АССР ның XX еллыгын үткәрүгә хәзерлек буенча бер генә комиссия дә төзелмәгән. Бу әһәмиятле датага хәзерлек мәсьәләсе белән район хезмәт ияләре таныштырылмаган һәм алар арасында масса-аңлату эше алып барылмый. Чистай район комиссиясе председателе иптәш Жуков хәтта үзе дә бу мәсьәләнең политик әһәмиятен аңлап җиткермәгән.

Татарстанның данлыклы юбилеенә хәзерлек буенча башка районнарда булган мөмкинлекләр Чистай районында да бар, ләкин Чистай район комиссиясе бу мәсьәлә белән шөгыльләнми, практик эш алып бару урнына коры лыгырдау белән вакыт үткәрә.

Хөкүмәт комиссиясе, Чистай район комиссиясенең хурлыклы рәвештә артта баруын гаепләп, киләсе 10 көн эчендә үз эшен юлга салуын һәм Татарстанның XX еллыгына хәзерлек буенча эшен яхшырту өчен практик чаралар билгеләвен таләп итте.

Шулай ук утырыш, Татарстанның XX еллыгына хәзерлек буенча Татарстан Мәгариф Халык Комиссары иптәш Контюковның докладын тыңлады. Аннары, республиканың юбилее унае белән, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почетлы грамотасы белән бүләкләү өчен алдынгыларны күрсәтү буенча подкомиссия председателе иптәш Матвеевның белдерүен тыңлады.

ЧИМАЛНЫ САКЛЫК БЕЛӘН ТОТАРГА, ҖИҺАЗЛАРДАН ТУЛЫ ФАЙДАЛАНЫРГА!

Хәзер безнең промышленностыбызда гаять бай техника тупланды. Производство техникасы һәм промышленность үсеше ягыннан куәтле Совет иле төп капиталистик илләрне узып китте. Безнең бурычыбыз капиталистик илләрне экономик яктан да узып китүдән гыйбарәт. „Без төп капиталистик илләрне экономик яктан узып киткән хәлдә генә илебезнең кулланy әйберләре белән тулысынча тәэмин ителүенә, бездә продуктларның мул булуына, һәм коммунизмның беренче фазасыннан аның икенче фазасына күчү мөмкинлегенә ирешүебезгә исәп тота алабыз“ (Сталин). Бу бөек бурычны үтәү өчен хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да югарырак күтәрергә, производство техникасын өзлексез яхшырта барырга кирәк. Моның өчен бездә бөтен шартлар, чикләнмәгән мөмкинлекләр, бай резервлар бар.

1940 нчы хуҗалык елы Совет иле халкының гүзәл инициативасы белән, производство активлыгының яңа күтәрелеше белән башланды. Башкалабызның инструменталь заводы эшчеләре һәм инженер-техник работниклары коллективы хезмәт җитештерүчәнлегенең өченче бишьеллык планын дүрт елда үтәү өчен көрәшкә чакырып, барлык хезмәт ияләренә мөрәҗәгать итте. Аларның бу чакырулары халык хуҗалыгының барлык тармакларында хезмәт җитештерүчәнлегенең яңа күтәрелешен, стахановчылык хәрәкәтенең тагын да киңрәк колач белән алга баруын тудырды. Предприятиеләрнең стахановчылары, эшчеләре һәм инженер-техник работниклары күбрәк санда продукция эшләп чыгару, продукциянең эшләнү бәясен киметү, чималга, материалларга экономия ясау, машиналардан, станоклардан тулы файдалану буенча социалистик йөкләмәләр алдылар.

Казан мехкомбинаты коллективының инициативасы буенча орденлы Татарстанның хезмәт ияләре республикабызның данлыклы XX еллыгына производство бүләкләре хәзерлиләр, социалистик ярыш байрагын тагын да югарырак күтәрәләр.

Чималны, материалларны саклык белән тотканда, артык расходларны кыскартканда, җиһазлардан иң яхшы файдаланганда без һәрбер предприятиедә өстәмә рәвештә киң куллану товарлары җитештерә алабыз. Ленин исемендәге завод, „Спартак“ комбинаты һ. б. предприятиеләр социалистик йөкләмәләр алганда гаять бай эчке мөмкинлекләргә зур игтибар биреп эш итәләр. „Спартак“ комбинаты ярым фабрикатны саклык белән тоту буенча гына да быел өстәмә рәвештә 30.000 пар аяк киеме эшләп чыгарырга булды.

Безнең алдынгы стахановчыларыбыз машиналардан, станоклардан файдалануның сокланырлык үрнәкләрен күрсәтәләр. Стахановчылык хәрәкәтенә яңалык кертүчеләр — күп станокларда эшләүчеләр эш сәгатьләреннән тулы файдаланып, техникадан тулы файдаланып хезмәт җитештерүчәнлегенең яңадан-яңа күтәрелешен тудыралар. Серго исемендәге заводта байтак эшчеләр күп станокларда эшләүгә күчтеләр. Бу заводның стахановчысы иптәш Максимова ике станокта эшләп, норманы 300—350 процент итеп үти. Шул ук заводның стахановчысы иптәш Зиннуров күп станокта эшләүгә күчкәнче цехта җиһазларны дөрес урнаштыру буенча зур яңалыклар кертте. Бу яңалыклар аңа детальләрне җитештерү өчен китә торган вакытка шактый күп экономия ясау мөмкинлеген бирделәр. Ул хәзер иң катлаулы производствода берьюлы 3 станокта эшли. Серго Орджоникидзе исемендәге завод стахановчысы иптәш Фирсов үзе башкара торган процесста продукция җитештерүнең технологиясен яхшырту буенча сигез төрле яңалык кертте. Шуның нәтиҗәсендә, ул норманы көн саен өч-дүрт тапкыр арттырып үтәүгә ирешә.

Безнең предприятиеләребездә мондый алдынгылар, яңалыкны башлап йөрүчеләр аз түгел. Предприятие җитәкчеләренең, инженер-техник работникларының, партия һәм профсоюз оешмаларының бурычлары производство алдынгыларының бөтен уңышлы тәҗрибәләрен барлык эшчеләргә күчерү буенча бөтен шартларны тудырудан, булышлык күрсәтүдән гыйбарәт.

Эчке мөмкинлекләрдән тулы файдалануга игтибарны көчәйтергә, барлык һәм һәр төрле хуҗасызлыкка каршы көрәшне көчәйтергә кирәк. „Без, кечкенәләрдән алып зурларына кадәр, үзебезнең барлык работникларыбызның дәүләт һәм халык каршында җаваплы булуларын һәр вакыт истә тотуларына, халык байлыгын саклауда һәм аның белән хуҗаларча эш итүдә, расходларга экономия ясауда һәм халык акчасын чынлап саклауда үзләренең бурычларын һәр вакыт исләрендә тотуларына ирешергә... Ягулыкны сакларга, чимал расходына экономия ясарга, җиһазларны сакларга, машиналарны яхшы карарга, агачны һәм төзү материалларын әрәм-шәрәм итмәскә тиешбез“ (Молотов).

Чималга, материалларга экономия ясауның юллары бик күп, әлбәттә. Шулардан иң әһәмиятлеләре—һәрбер предприятиедә ныклы хуҗалык тәртибе урнаштырудан, материалларга төгәл учет булдырудан, аларны дөрес саклаудан, материалларны тотуда контрольне көчәйтүдән гыйбарәт. Бу, үз чиратында, производство культурасын яхшыртуга бик нык бәйләнгән. Ләкин кайбер предприятиеләрнең җитәкчеләре бу тармакта үзләренең бурычларын тулы үтәмиләр әле.

Мисальгә киез итек фабрикасын алырга мөмкин. Бу фабрикада чималның, материалларның дөрес учеты юк. Шунлыктан, цехларда чималның әрәм булу фактлары бар. Мондый тәртипсезлек түшәү цехында күбрәк күренә. Цех җитәкчеләре йонга экономия ясау турында бөтенләй уйламыйлар. Итекләрнең күп өлеше кирәгеннән тыш калын яисә кирәгеннән тыш озын кунычлы була. Шуның нәтиҗәсендә ай саен күп тонналар йон әрәм-шәрәм ителә. Мондый фактлар башка предприятиеләрдә дә юк түгел.

Бурыч,—барлык предприятиеләрдә дә бары тик югары сыйфатлы продукция эшләп чыгарудан гыйбарәт. Продукциянең сыйфаты яхшы һәм отлично булганда гына айлык яисә квартал планы үтәлгән булып исәпләнә ала. Бу төп шартны бер генә минутка да онытырга ярамый.

Безнең илебездә Сталинчыл Өченче Бишьеллык исемендәге социалистик ярыш яңа көч белән алга бара. „Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү буенча өченче бишьеллык планны дүрт елда үтәргә!“—куәтле Совет илендә яшәүче хезмәт ияләре лозунгысы әнә шул. Бу гигант бурычны үтәү безнең предприятиеләребездәге барлык төр чималдан, производство материалларыннан, җиһазлардан иң яхшы рәвештә файдалануга, аларны саклык белән тотуга бик нык бәйләнгән. Гаять бай эчке мөмкинлекләрдән тулы файдаланыйк, илебезнең экономикасын һәм оборона куәтен тагын да ныгытыйк.

Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә хәзерлек

ӨЧ МЕҢГӘ ЯКЫН ГАРИЗА

Республикабызның колхозчылары, МТС һәм совхоз эшчеләре, авыл хуҗалыгы белгечләре 1940 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашу хокукын яулап алу өчен җидди хәзерлек алып баралар. Күргәзмәдә катнашуны сорап Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариатына барлыгы өч меңгә якын гариза алынды. Алар арасында 10 МТС, бөртекле культуралар буенча 188 колхоз, 131 терлекчелек фермасы һәм башкалар бар. 2.155 гариза механизация, игенчелек, терлекчелек һәм башка эш тармакларында эшләүче алдынгылардан алынды. 200 экспонентны Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенең Баш Комитеты күргәзмәгә катнашуга кандидат итеп раслады. Хәзер калган гаризаларны рәсмиләштерү эше алып барыла.

Күргәзмәдә катнашуга экспонентлар сайлап алу буенча Сарман һәм Актаныш районнары алдынгы урында баралар. Бу районнарның беренчесеннән 339, икенчесеннән 286 гариза алынды. Тымытык һәм Минзәлә районнары да бу эштә республика күләмендә өченче һәм дүртенче урында баралар.

Шуның белән бергә, кайбер районнарда күргәзмәгә экспонентлар сайлап алу эше бөтенләй башланмаган диярлек. Мондый районнар рәтенә Ширәмәт, Биләр, Бөгелмә, Кама Тамагы, Аксубай районнары керәләр. Бу районнардан хәзергә кадәр әле дүрт-биш гариза гына кергән. Ә Юдино һәм Алабуга районнары берәр гариза җибәрү белән тынычланып калганнар. Бу хурлыклы күрнеш, һич шиксез, район җитәкчеләренең, бигрәк тә район җир бүлеге работникларының күргәзмәгә хәзерлек эшен ачыктан-ачык үз агымына куюларының нәтиҗәсе.

Күргәзмәгә хәзерлек дәүләт күләмендә гаять зур әһәмияткә ия булып тора. Аны үз агымына куярга ярамый. Ул язгы чәчүгә хәзерлек белән нык бәйләп алып барылырга тиеш. Һәрбер район җитәкчесе, җир органнарында эшләүче һәрбер работник үз эшенә карата моннан тиешле нәтиҗә ясарга тиеш.

ЯРЫШТА АЛДЫНГЫЛЫК ӨЧЕН

(Хәбәрче хатлары буенча)

Югары иген уңышы өчен көрәштә саен 8 миллиард пот ашлык җитештерүгә ирешү турында бөек Сталин күрсәтмәсен үтәү өчен көрәштә үткән ел илебездә яңа хәрәкәт—йөзпотчылар хәрәкәте барлыкка килде. Бу хәрәкәт хәзер Татарстан республикасы колхозларында, совхозларында да җәелә.

„Көчле ирек“ колхозының (Норлат районы) 10 нчы бригадасы бригадиры иптәш **Зияттинов** үзенең бу өлкәдәге эше турында түбәндәгеләрне яза:

„Минем бригада үткән ел бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 19,96 центнер уңыш алды. Без бу уңышка агротехника чараларын дөрес үткәрү, чәчү һәм урып-җыю эшләрен кыска срокта башкару нәтиҗәсендә ирештек. Үткән елгы тәҗрибәдән чыгып, быел тагын да югарырак уңыш алу өчен көрәшәбез. 4 даими звено оештырдык. Алар барсы да үзара ярышып эшлиләр. Язгы чәчүгә кирәкле орлыклар һәм инвентарьлар хәзер. Басуга 772 йөк тирес чыгардык. Планда билгеләнгән 37 центнер урынына 58 центнер фекаль хәзерләдек, 17 центнер урынына 38 центнер кош тизәге, 25 центнер көл җыйдык. Планда каралмаган булса да, 50 центнер компост ашлама хәзерләдек. Участкыларда тотылган карның калынлыгын 130 сантиметрга җиткерү чарасын күрәбез. Бригада членнары стахановчылар мәктәбендә укыйлар“.

Буденный районыннан хәбәрче иптәш Яфизов „Азат“ колхозы членнарының һәр гектардан йөз пот уңыш алу өчен зур бердәмлек белән хәзерләнүләре турында яза:

„Колхозчылар,—ди иптәш Яфизов,—агротехника чараларын үткәрү буенча колхоз правлениесенең наряд бирүен көтеп тормыйлар. Алар теге яки бу чараны үткәрүдә үзләре инициатива күрсәтәләр. Райзо планы буенча бирәдә 800 гектарда кар тотылырга тиеш иде, ә колхозчылар 1.215 гектарда кар тоттылар. Басуда тотылган карның тирәнлеге урны-урны белән 1 метрга җитә. Колхозчылар көл, кош тизәге шикелле җирле ашламаларны җыюга зур әһәмият бирәләр. Мондый ашламаларны үз хуҗалыгында җыеп тапшыручыларга правление хезмәт көннәре яза. Агротехник иптәш Хәйсаров колхозчылар арасында зур авторитет белән файдалана. Ул агротехника укуларына җитәкчелек итә, төрле тәҗрибәләр алып бара“.

Шушындый матур фактлар турында язып, хәбәрче иптәш **Абдуллин** болай ди: „Чаллы районы, „Кызыл Юл“ колхозы членнары Калинин районы авыл хуҗалыгы алдынгыларының мөрәҗәгатенә кушылып, бодай һәм арыш культураларының һәр гектарыннан 18 әр центнер, солының һәр гектарыннан 16 центнер уңыш алырга йөкләмә алганнар иде. Алар бу йөкләмәләрен намус белән үтәү өчен көрәшәләр. Чәчү орлыклары җитәрлек хәзерләнде һәм чистартылды. Машиналарга, инвентарьларга һәм ат сбруйларына яхшы сыйфатлы ремонт ясалды. Агротехника чараларын үткәрү һәм җирле ашламалар җыю эше уңышлы бара“.

Норлат районыннан язучы хәбәрче Афзал иптәш **Җәләлиев** „Активист“ колхозының орденлы иптәш Кәримев җитәкчелегендәге бригадасында гектар саен 22 центнер бөртекле иген уңышы алу өчен көрәшнең зур оешканлык белән баруын күрсәтә.

Җир органнары, партия һәм совет оешмалары җитәкчеләре гектардан йөз пот уңыш өчен көрәшнең башында булырга, аңа җитәкчелек итәргә тиешләр.



Татнаркомземнан район җир бүлекләренә һәм колхоз производствосына даими эшкә китүче авыл хуҗалыгы белгечләреннән бер төркем. РӘСЕМДӘ (сулдан уңга): Г. Камалова, Г. Р. Терегулов һәм В. Н. Евстафьев иптәшләр.

И. Галиев фотосы.

Авыл хуҗалыгы белгечләре производствога!

Хәзерге көндә Татарстанның район җир бүлекләре, МТС лары һәм колхозлары өчен 500 дән артык авыл хуҗалыгы белгечләре—агрономнар, зоотехниклар, ветврачлар һәм башкалар җитешми. Моның төп сәбәбе мондый кадрлар булмауда түгел, бәлки кадрлардан дөрес файдалана белмәүдә, аларга уңайлы эш шартлары тудырмауда һәм аларны производство таләпләренә туры китереп урнаштыра белмәүдә. Уку йортларын тәмамлап чыккан күп кенә белгечләр производствога китмичә, аппаратта утырып калалар яки үз белгечлекләрен ташлап башка эшкә китәләр. Наркомземда булган мәгълүматларга караганда, Татарстандагы авыл хуҗалыгы белгечләреннән югары һәм урта белемле 417 кеше бөтенләй башка тармакларда эшли.

Менә берничә факт. 1939 нчы елда Ключище авыл хуҗалыгы техникумын тәмам итеп чыккан иптәш Хөснуллина ВКП(б) ның Югары Ослан райкомында техник секретарь булып эшли. 1936 нчы елда Чистай авыл хуҗалыгы техникумын тәмам итеп чыккан Фатыйма иптәш Кәримова Саба районында кладовщик булып эшли. Элек Авыл Хуҗалыгы техникумын, аннан соң Авыл Хуҗалыгы институтын тәмамлап чыккан иптәш Хәсәнев хәзер 4 нче ясалма каучук заводында смена начальнигы. Минзәлә районында 25 тән артык агроном һәм зоотехниклар үз белгечлекләре буенча эшләмиләр. Ә шул ук вакытта районда ике зоотехник җитешми. Кызганычка каршы, мондый мисальләрне күпләп китерергә мөмкин.

Соңгы вакытта аппаратта яки үз белгечлекләреннән башка тармакта эшләп тә, үзләренең төп эш урыннары МТС та, совхозда, колхоз производствосында икәнен аңлап, Казаннан 30 лап белгеч производствога китте. Ләкин бу бик аз. Үзләренең гражданлык бурычларын намус белән үтәргә теләүче алдынгы белгечләр бездә күп. Ләкин масса тарафыннан күтәрелгән инициативаның башында торырга тиешле Татарстан Наркомземы бу эш белән әле һаман да чын-чынлап шөгыльләнгәне юк.

СССР Җир Эшләре Халык Комиссары иптәш Бенедиктов өлкә, край, җир бүлекләренең начальникларын, союзный һәм автономияле республикаларның наркомнарын, югары уку йортларының, фәнни тикшерү институтларының һәм башка учреждениеләрнең директорларын үз аппаратларындагы югары һәм урта белемле белгечләрнең яртысыннан күбрәген производствога җибәрергә мәҗбүр итеп приказ чыгарды. Приказның чыгуына айдан артык вакыт үтеп китсә дә, Татарстан Наркомземында бу күрсәтмәне тормышка ашыру буенча әле һаман да күзгә күренерлек эш юк. Наркомзем аппаратында 100 гә якын төрле белгечләр бар. Боларның 10 проценты да әле производствога җибәрелмәгән. Бирәдә штат күпертергә, үз тирәсенә күп санда кешеләр тупларга, кочак-кочак кәгазьләр язарга гадәтләнгән кайбер начальниклар, мөдирләр әле һаман да бу начар тенденция сөременнән арынмаганнар, күрәсең. Ә Наркомзем бу эшкә турыдан-туры җитәкчелек итәргә тиеш. Бу бер.

Икенчедән, урындагы партия, совет оешмалары һәм җир органнары производствога килүче белгечләргә тормыш-көнкүреш ягыннан бөтен уңайлы шартларны тудырырга тиешләр. Белгеч урынга килгән көннән үк бары тик гомуми интерес өчен файдалы эш белән генә шөгыльләнерлек булсын. Квалификацияле работникларга, белгечләргә җансыз караш фактларын булдыруга юл куючыларга каршы рәхимсез рәвештә көрәшергә кирәк.

А. Вәлиев.

ЯХШЫ УКЫТУЧЫ ҺӘМ АКТИВ ҖӘМАГАТ ЭШЧЕСЕ

Иптәш Сиражиев Кече Шәйморза авылындагы Буденный районы башлангыч мәктәптә инде 9 ел укыта. Аны авылның кече яштәге балалары да, картлары да яхшы беләләр, үз туганнары кебек яраталар.

Ул, яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләүгә бөтен көчен һәм энергиясен бирә. Шуның өчен дә уку елының беренче яртысында ул укыткан класслар (1 нче һәм 3 нче класс) 100 процент өлгереш бирделәр.

Иптәш Сиражиев яхшы укытучы һәм актив җәмагат эшчесе. Ул колхозчылар арасында масса-агитация эшләре алып бара, төрле темаларга докладлар ясый, беседалар үткәрә һәм стена газеталары чыгара. Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар вактында иптәш Сиражиев масса арасында зур эш алып барды.

Аның инициативасы буенча колхозда агрономия белемен өйрәнү түгәрәге оештырылды. Бу түгәрәккә иптәш Сиражиев үзе җитәкчелек итә һәм 11 тапкыр занятие үткәрде инде. Түгәрәккә колхозчылардан 25 кеше бик кызыксынып йөри, шуларның 12 се хатын-кызлар. Иптәш Сиражиев агротүгәрәк җитәкчесе булып 9 ел буенча эшләп килә. Эшләнгән эшнең гүзәл нәтиҗәләре дә бар. Мәсәлән, „Кызыл Сабанчы“ колхозы 1939 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашты һәм икенче дәрәҗә диплом, 5 мең сум акча һәм мотоцикл белән бүләкләнде. Язгы чәчүгә хәзерлек эше колхозда быел да үрнәк булырлык итеп оештырылган.

Авылда уку өе булдырылды. Ул матур итеп җиһазландырылды һәм газета-журналлар алдырыла. Монда да иптәш Сиражиев зур эш алып бара. Халыкара хәл турында беседалар үткәрә, газета-журнал укуны оештыра.

Кыскасы, иптәш Сиражиев үрнәк булырлык яхшы укытучы һәм актив җәмагат эшчесе.

А. Яфизов.

ВАГДӘ ҺӘМ ЧЫНБАРЛЫК

Татар язуын рус графикасы нигезендә яңа алфавитка күчерү турында Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының указы буенча эш башкаруны рус һәм татар телләрендә алып бара торган дәүләт учреждениеләре, предприятиеләр һәм җәмагат оешмалары татар телендә эш башкаруны яңа алфавитка шушы елның 1 нче январеннан күчерергә тиешләр иде.

Ләкин, Норлат районының кайбер учреждениеләре бу указны тормышка тулысынча ашырудан ерак торалар әле. Район советы башкарма комитетының гомуми бүлеге (мөдире иптәш Мирсикаева) татар телендә алып барыла торган бөтен эшне иске алфавит буенча йөртә. Райсоветның башкарма комитетыннан авыл советларының башкарма комитетларына җибәрелә торган эш кәгазьләре дә иске алфавитта языла лар. Райуполнаркомзаг работниклары хезмәт ияләреннән яңа алфавит буенча язылып килгән эш кәгазьләренә иске алфавит буенча җавап язып җибәрәләр.

Районда рус графикасы нигезендәге яңа алфавитны өйрәнү һәм аны тулысынча үзләштерү эше тиешле дәрәҗәдә оештырылмаган. Районның җитәкче работникларыннан Гыймранов (район җир бүлеге мөдире), Гыйлаҗев (райпотребсоюз председателе), Низамиев (ВКП(б) райкомының кадрлар бүлеге мөдире), Нурмиев (ВЛКСМ райкомының оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире) һәм башка кайбер иптәшләрнең яңа алфавитны бу көнгә кадәр үзләштермәүләре моны бик ачык күрсәтә.

Район мәгариф бүлеге мөдире иптәш Җәләлиев яңа алфавитны өйрәнү буенча түгәрәкләр оештыру турында үткән елның сентябрь аеннан бирле сөйләп йөри, күп вәгъдәләр бирә, ләкин бу сөйләнүләр коры лыгырдану булып калалар, түгәрәкләр оештырылмый.

Татар халкы культурасының үсешендә прогрессив чара булып торган яңа алфавитны өйрәнүгә һәм аны яхшы үзләштерүгә, бу турыда Верховный Совет Президиумының указын тормышка тулысынча ашыруга ирешү өчен ВКП(б) ның Норлат райкомы конкрет чара күрергә тиеш. Бу мәсьәләгә карата булган коры лыгырдануны бетереп, тиешле эш таләп итәргә вакыт инде.

Х. Хәлилев.

Минзәлә театры

Минзәлә колхоз-совхоз театры 1939 нчы елда барлыгы 397 спектакль куеп, шулардан 272 се зурлар һәм 125 е балалар өчен булды. Театр Н. А. Островскийның „Гаепсездән гаеплеләр“ен, М. Горькийның „Васса Железнова“сын, орденлы драматург Т. Гыйззәтнең „Мактаулы заман“, „Чаткылар“ дигән әсәрләрен һ. б. әсәрләрне куйды. Спектакльләр колхозчы масса тарафыннан күтәренке рух белән каршы алындылар. Шуның нәтиҗәсендә, театр 1939 нчы елда алдынгы колхоз-совхоз театрлары сафына басып, Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашты.

Театр коллективы 1940 нчы елда яңа уңышлар яулап алу өчен җиң сызганып эшкә керәште. Хәзерге көндә театрның ике бригадасы Татарстанның Әгерҗе, Актаныш, Красный Бор, Калинин, Минзәлә һәм башка районнарда культура хезмәте күрсәтеп йөри. Беренче бригада Америка тормышыннан алынып язылган „Улкаем“ дигән комедияне, икенче бригада башлап язучы С. Хәсни иптәшнең МТС тормышыннан алып язылган „Биктимер“ дигән пьесасын күрсәтә. Болардан тыш тагын зурлар һәм мәктәп балалары өчен аерым концертлар куелып, ул концертларда украина, рус, татар биюләре башкарыла һәм татар совет шагыйрьләренең шигырьләре укыла.

Театрның бу ике бригадасы үзара ярышып эшлиләр. Коллективта оборона эшләренә нык игътибар бирелә, хәрби занятиеләр һәм халыкара хәл турындагы мәсьәләләр буенча лекцияләр үткәрелә. Бу чараларны үткәрүдә ВКП(б) ның Актаныш һәм Ворошилов райкомнары театр коллективына зур ярдәм иттеләр һәм итәләр. Театр колхозларның үзешчән сәнгать түгәрәкләренә иҗади ярдәм күрсәтеп килә.

Артистларның гомуми белемнәрен күтәрү буенча аерым дәресләр үткәрелә, алар „СССР тарихы“, „Рус әдәбияты тарихы“ һәм „Борынгы тарих“ фәннәрен өйрәнәләр. Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар вактында театр сайлаучыларга концерт һәм берничә спектакль куйды. Театрның артисткасы Рәбига иптәш Токанаева Минзәлә шәһәр Советына депутат итеп сайланды.

Ләкин артистларның политик белемнәрен күтәрү, ВКП(б) тарихын өйрәнү эше тиешенчә куелмаган. Комсомол оешмасы, күпчелеге яшьләрдән торган театр коллективына, бу эштә җитәрлек ярдәм күрсәтми.

Сүз ахрында тагын шуны да әйтеп китәргә кирәк: театрның 1940 нчы ел өчен төпле репертуар планы юк әле. Татарстанның Сәнгать Эшләре Идарәсе бу турыда ни уйлый икән?

Г. Бикмул.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ҺӘМ ХӘРБИ ДИҢГЕЗ ФЛОТЫНЫҢ XXII ЕЛЛЫГЫ АЛДЫННАН

Кызыл Армия һәм халык

Ленин һәм Сталин партиябезнең бөтен тарихында халыкны коралландыру мәсьәләсенә гаять зур игътибар бирделәр. 1905 нче елгы революция алдыннан Ленин, кораллы көчләрдән башка царизмны бәреп төшереп һәм буржуазияне җиңеп булмый, дип язды. Ильич революция яшененең беренче билгеләре күренү белән үк коралланырга чакырып эшчеләргә мөрәҗәгать итте. „Бары тик коралланган халык кына халык азатлыгының чын терәге була ала“ дип язды Ленин. Эшчеләр массасы бу мөрәҗәгатьне гаять зур күтәренкелек белән каршы алды. Эшчеләр үзләренең кораллы дружиналарын төзү эшенә керештеләр.

1917 нче елгы Февраль Революциясе чорында, Ленин—Сталин җитәкчелегендәге партиябез зур шәһәрләрдә Кызыл Гвардиянең кораллы отрядларын төзи башлады. Һәрбер эшче Кызыл гвардеец дигән исемне йөртүне үзе өчен гаять зур хөрмәт дип санады.

Советлар республикасына империалистик дәүләтләрнең һөҗүм итү мөмкинлеген алдан ук күреп, Ленин һәм Сталин Совет властенның беренче көннәреннән үк эшчеләрдән һәм крестьяннардән яңа, яхшы оештырылган революцион армия төзү бурычын куйдылар.

Эшче-Крестьян Кызыл Армиясен оештыру турында 1918 нче елның 28 нче январенда Ленин кул куйган декретта болай диелә:

„Иске армия буржуазия тарафыннан хезмәт ияләрен сыйнфи яктан изү коралы булып хезмәт итте. Власть хезмәт ияләре һәм эксплоатацияләнгән сыйныфлар кулына күчү белән, яңа армия төзү кирәклеге туды, бу армия Совет властеның терәге булыр, якын киләчәктә даими армияне бөтен халыкны коралландыру белән алмаштыру өчен чын фундамент булыр һәм Европада булачак Социалистик Революция өчен яклаучы булып хезмәт итәр“.

Кызыл Армия башта добровольцлардан төзелде. Ак гвардеецлар һәм интервентлар берләштеләр, алар яшь советлар республикасына һөҗүм иттеләр. Бу хәл безне мәҗбүри хәрби хезмәткә күчәргә мәҗбүр итте.

Ленин, Сталин тарафыннан төзелгән яшь Кызыл Армия төзелүенең беренче көннәреннән үк, баштан аяк коралланган империалистик ерткычларга каршы рәхимсез көрәшкә чыкты һәм аларны тар-мар итте. Кызыл Армия кешелек дөньясы тарихында үзенә мәңгелек дан казанды һәм бөтен халык мәхәббәтен яулап алды.

Бездә, Советлар илендә, халык армияне ярата, аның турында өзлексез кайгыртучанлык күрсәтә. Бу бик аңлаешлы. „... Безнең Кызыл Армиябезне аерып торган шундый үзенчәлеге бар ки, ул эшчеләр һәм крестьяннар властеның ныклыгын саклау коралы булып, пролетариат диктатурасының ныклыгын саклау коралы булып, эшчеләрне һәм крестьяннарне алпавытлар һәм капиталистлар коллыгыннан азат итү коралы булып хезмәт итә. Безнең армиябез хезмәт ияләрен азат итү армиясе“ (Сталин).

Бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинның бу сүзләрен Кызыл Армиябез Хасан күле районындагы, Халхин-Гол елгасы янындагы сугышларда, Көнбатыш Белоруссиядәге һәм Көнбатыш Украинадагы туганнарыбызны азат итү моментында аклады. Кызыл Армия юлбашчыбызның бу сүзләрен хәзер фин халкын азат итү өчен ак финнәргә каршы көрәштә аклый. Менә Кызыл Армиябезгә карата халык мәхәббәтен чагылдыра торган бер эпизод.

„Сугыштан соң тын алу өчен Тарнополь урамнарының берсенә тукталдык,—ди танкист иптәш Седов.—Танк янына халык җыелды. Мин машинадан чыктым һәм сөйләшүләр башланды. Нак шул вакытта балконнан мина револьвердан ата башладылар. Ату тавышлары ишетелү белән үк халык мине чолгап алды, күкрәге белән мине пуләдән саклады. Дошманга каршы яңадан ыргылу өчен халык боҗрасыннан чыгарга никадәр генә омтылып карасам да, булдыра алмадым. Бер хатын миңа: „Нәрсә сез, улым! Безгә синең каның кадерле. Сез безгә тормыш алып килдегез! диде“.

Бу хатынның шушы гади, кыска һәм чын күңелдән әйтелгән сүзләре куәтле Кызыл Армиябез үти торган бөек азатлык роленең әһәмияте никадәр зур икәнлекне бик ачык һәм матур итеп чагылдыралар.

Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенә карата хезмәт ияләренең ялкынлы мәхәббәте һәр нәрсәдә ачык күренә. Совет яшьләре Кызыл Армиябезгә һәм хәрби училищеләргә зур омтылыш һәм зур күтәренкелек белән баралар.

Бездә Кызыл Армиягә, Хәрби Диңгез Флотына һәм НКВД гаскәрләренә призыв бөтен халык бәйрәме булып әверелә. Яшь патриотларны Кызыл Армиягә озатканда ата-аналар һәм туганнар иң яхшы хисләр белән тулган сүзләрне әйтәләр.

Иптәш Чиркин улын Кызыл Армиягә озатканда: „Кадерле улым, син бүген Кызыл Армиягә барасың. Безнең таза һәм культуралы тормышыбызны иптәш Сталин өйрәткәнчә сакла. Мин производствода стахановчы булып эшләрмен“ диде.

Призывник анасы Никифрова улына армиядән коммунист булып һәм Советлар Союзы Герое булып кайт, дип наказ бирде.

Куйбышев районының Пичкас авылы колхозчысы яшь сугышчыларны армия сафына озату җыелышында болай диде:

„Минем хәзер ике улым кызыл армеец, алар япон самурайларына каршы батырларча көрәштеләр. Бүген армия сафына өченче улымны озатам. Улларыма наказым шул: дошманнарны нык кыйнагыз, башкаларына сабак булырлык итеп кыйнагыз!“.

Яшь сугышчы Савицкий боевой листокка язган мәкаләсендә болай ди:

„1919 нчы елны ак гвардеецлар атам белән анамны үтергәннәр. Хәзер мин социализм иленең сугышчысы. Ленин—Сталин партиясе өчен мин ак финнәргә каршы көрәштә тормышымны да кызганмам“.

Халкыбызның Кызыл Армиягә һәм Кызыл Армиянең халкыбызга карата чиксез мәхәббәте турында мондый фактларны һәм мисальләрне бик күп китерергә мөмкин. Алар барсы да бер нәрсә турында сөйлиләр: „Безнең халкыбыз тынычлыкны ярата, аның бөек нәтиҗәләренең кадерен белә һәм бөтен дөньяда тынычлык өчен көрәшә. Ләкин ул сугыша да белә. Белә генә түгел, бәлки сугышырга ярата да. Әгәр дә йөгәннәреннән ычкынган агрессорлар кайчан да булса совет халкын коралга тотынырга мәҗбүр итсәләр, ул, моннан 17 ел элек үзенең дошманнарын ничек кыйнаган булса, хәзерге вакытта үзенең социалистик яңа тормышын ничек төзесә, шундый ук дәрт һәм осталык белән сугышыр һәм тулысынча һәм тәмам җиңми торып коралын ташламас“ (Ворошилов).

Моны безнең армиябез генә эшли ала. Чөнки Советлар иле армиясенең сугышчысы—ул бер фикер, бер омтылыш белән, халыкка мөмкин кадәр яхшы хезмәт итү теләге белән сугарылган. Бездә армия һәм халык бер бөтен, бер семья. Иптәш Сталин җитәкчелек итә торган бу армия җиңелмәслек.

Полковой комиссар

М. Мишнев.

Ужымнарның кышлавы

Метеорология станцияләре ужымнарның ничек кышлавын системалы рәвештә тикшереп торалар.

Татарстан метеорология станцияләре тарафыннан үткәрелгән соңгы тикшерү материалларына караганда, Казан тирәсендә, Мөслим, Чүпрәле, Октябрь һәм Бөгелмә районнарында арыш ужымы тулысынча сакланган. Иртә чәчелгән һәм көз көне яхшы тишелеп калган урыннарда һәр җирдә диярлек ужымнарның торышы яхшы. Соңга калып чәчелгән һәм кар катлавы юка булган урыннардагы ужымнар 2—7 процент сирәкләнгәннәр. Минзәлә районында исә арыш ужымы 10 процент сирәкләнгән, Казан тирәсендә, Бөгелмә районында һәм башка күп кенә районнарда тукранбаш яхшы саклана.

Кар күбрәк яуган районнарда арыш һәм бодай ужымнарының кышлавы бигрәк тә яхшы. Хәзерге көндә Татарстанның күп районнарында кар катлавының калынлыгы 19—27 сантиметрга, Арча, Дөбъяз һәм Татарстанның төньяк-көнбатышындагы башка районнарында 28 сантиметрга, Бөгелмә районында 40 сантиметрга җитә.

КОЛХОЗЛАРНЫҢ ДОХОДЫ ҮСӘ

Мөслим районының „Туры юл" колхозы (председателе иптәш Хәкимев) 1939 нчы елда смета буенча 187 мең 200 сум акча доходы аласы урынга 189 мең 800 сум доход алды.

„Туры юл" колхозы доходны үстерүдә барлык мөмкинлекләрдән файдалана. Колхозда тула басу, кирпеч сугу һәм извест яндыру кебек эшләр оештырылды. Шушы чараларны үткәрүдән колхоз 35 мең сум доход алды. Бу предприятиеләрдә еллык план 130 процент итеп үтәлде.

Колхозчыларның 1939 нчы елгы хезмәт көннәренә акчалата доход бүлү тәмам булды. Һәр хезмәт көненә 60 тиен акча тиде. Стахановчылардан иптәш Имамиев 687 сум, Габдрахманов 475 сум, А. Газетдинов 444 сум акча алдылар.

Д. Бурангаев.

Этнә районының „Симетбаш" колхозы членнары доход бүлделәр. Колхозчылар һәр хезмәт көненә 2 шәр килограмм бөртекле ашлык алдылар.

Мөхәммәтҗан иптәш Акберов семьясе 177 пот, Сафа иптәш Сибгатуллин семьясе 155 пот, иптәш Ахметҗанов семьясе 135 пот ашлык алдылар.

Р. Вафин.

БАЛАЛАР БАКЧАЛАРЫ

Хәзерге көндә Казанда һәм районнарда 750 балалар бакчасында 34.944 бала тәрбияләнә. Хөкүмәт карары буенча быел бакчаларның саны 910 га кадәр арттырыла. Аларда тәрбияләнүче балалар саны 38.000 гә җиткереләчәк. Чистайда, Бөгелмәдә һәм Кукмарада балалар бакчалары өчен яңа бина̀лар төзелә.

Җәй көне колхозларда һәм совхозларда 80.000 бала өчен 2.110 мәйданчык оештырылачак.



„Бөек гражданин" фильмысының икенче сериясеннән бер кадр. Крайкомның икенче секретаре Земцев кабинетындагы күренеш. Республиканың атказанган артисты орденлы Ю. Толубеев (уңда) Земцев ролендә һәм республиканың атказанган артисты Б. Пославский шофер Сизов ролендә.

А. Езерский фотосы (ТАСС фотохроникасы).

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ҺӘМ ХӘРБИ ДИҢГЕЗ ФЛОТЫНЫҢ XXII ЕЛЛЫГЫ АЛДЫННАН

ЗНАЧКИСТЛАР ХӘЗЕРЛӘҮ

Татарстанның Осоавиахим оешмалары Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгына шактый зур уңышларга ирештеләр.

1939 нчы елда Казанда һәм Татарстанның 45 авыл районында „ПВХО" значогының беренче баскычына 34.881 кеше, икенче баскычына 692 кеше норма тапшырды. ПВХО буенча значкистлар хәзерләү планы арттырып үтәлде. Казанда һәм районнарда 18.000 нән артык кеше катнашы белән 785 тапкыр тренировка үткәрелде. Противогазларда 157 тапкыр массовый поход оештырылды. Походларда 6.000 нән артык кеше катнашты.

ПВХО инструкторлары хәзерләү өчен декабрь аенда Бөгелмәдә, Чистайда, Алабугада, Тәтештә һәм Юдинода курслар ачылган иде. Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгына курсларны 133 кеше тәмам итеп чыга. Бәйрәм көннәрендә Казанда һәм районнарда противогазларда массовый походлар оештырылачак.

БӘЙРӘМ ХӨРМӘТЕНӘ

Казшвейпром артеле членнары, данлыклы бәйрәмне производствода яңа җиңүләр белән каршы алу өчен, айлык планны 23 нче февраль көненә үтәү турында йөкләмә алдылар.

Артельдә Ворошиловча атучылар түгәрәге оештырылды. Түгәрәк занятиеләренә барлыгы 20 кеше йөри. 10 кеше шушы көннәрдә генә „ГСО" значогына норма тапшырды. Хәзер артельдә „ГСО" значогына норма тапшыручылар саны 42 кешегә җитте. 25 кеше „ПВХО" значогына, 12 кеше „ГТО" значогына нормалар тапшырдылар. РОКК членнарыннан 15 кешелек кадровый дружина төзелде.

Коллектив 22 нче февральдә артельдә гомуми оборона көне үткәрү өчен зур хәзерлек эшләре алып бара.

Ф. С.

СТУДЕНТЛАРНЫҢ ЧАҢГЫ ЧАБЫШЫ

Кызыл Армиянең 22 еллыгына багышлап, Алабугада студентларның чаңгы чабышы үткәрелде. Чабышта көтепханә техникумы, педучилище, политик - агарту мәктәбе һәм башка мәктәпләр студентларыннан 56 кеше катнашты.

Ирләр өчен булган 10 километр дистанцияне 52 минут 0,1 секунд эчендә үтеп, көтепханә техникумы студенты иптәш Хөсәенов беренче урынны алды. Хатын-кызлар өчен 3 километрга үткәрелгән чабышта беренче урынны көтепханә техникумы студентларыннан Шәрәфетдинова һәм Уткина иптәшләр алдылар.

12 нче февральдә оборона-массовый эше активистларыннан торган группа Столбище районының Дәүләки авылына хәрбиләштерелгән чаңгы походы оештырдылар. Анда чаңгычылар Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының еллыгы турында колхозчылар белән беседалар үткәрделәр.

* * *

4 нче ясалма каучук заводы цехларының берсендә комсомолка-лаборантка иптәш Березинскаяның инициативасы буенча, „Ворошиловча атучы" значогына норма тапшыру түгәрәге оештырылды. Түгәрәккә 20 дән артык кеше йөри. Бу иптәшләр Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең 22 еллыгы көненә норма тапшыру эшен тулысынча тәмамлаячаклар.

ШАХМАТ ЧЕМПИОНАТЫ

ИКЕНЧЕ ТУР

Казан Шахмат чемпионатында беренчелек өчен көрәш кызганнан-кыза бара. Ничьяларның һәм кичектерелгән партияләрнең күп булуы моны бик ачык күрсәтеп тора. Һәр уенчы үзенең бөтен көчен куеп уйный һәм югары урынга омтыла.

Икенче турда да ике генә партия нәтиҗә белән тәмам булды. Нәҗметтинов Виноградовны җиңел рәвештә отуга ирешә. Турнир очрашуларында зур тәҗрибәле Колчуринның әле яңа гына күтәрелеп килә торган көчле шахматчы Сайгин белән очрашуы, һич шиксез, һәр ике як өчен бик әһәмиятле һәм җаваплы очрашу иде. Алар арасындагы партия соңгы моментка кадәр гаять кискен төстә барды. Ләкин, аклар (Сайгин) караларның ферзь флангысына көчле басым ясап, бер пешкаларын ферзьгә чыгаруга ирештеләр. Колчурин ладьясын бирергә һәм соңыннан бөтенләй бирелергә мәҗбүр булды. Шулай итеп, Сайгин, рәттән ике отышы белән, турнирның лидеры булып әверелде.

Яш шахматчылардан Кильматов—Хенкин һәм Нотариус—Вельтмандер арасындагы партияләр чама белән тигез хәлдә кичектерелде. Косолапов белән Щербаков арасындагы партия беренчесе өчен начар хәлдә кичектерелде.

3 нче тур 18 нче февральдә була.

Шашка чемпионатында лидерлыкны Нәҗметтинов үз кулында тота. Аның хәзер 3 уеннан 3 очкосы бар. Икенче категорияле Ивлиев беренче 2 турны зур күтәренкелек белән алып барып, беренче категорияле Алакшин һәм Елисеев иптәшләрне отты. Ләкин өченче турда ул үзенең уңышлы барышын дәвам иттерә алмады һәм „Спартак" спорт җәмгыяте вәкиле Сорокинга оттырды.

Х.

ЧЕРЕПИЦА ЗАВОДЛАРЫ

Түбә ябу өчен хәзерләнә торган черепица (чүлмәк түбә) төзү материалларының әһәмиятле төрләреннән берсе. Черепица белән ябылган түбә утта янмый. Ул шулай ук калайга һәм тактага экономия ясарга ярдәм итә.

Татстройматпромсоюзның Бөгелмәдәге заводы узган елны 300 мең данә черепица эшләп чыгарган иде. Быел Питрәч, Бөгелмә һәм Минзәләдәге заводларда 1 миллион 500 мең данә черепица житештереләчәк. Бу заводларга реконструкция ясалды. Черепица эшләү өчен машиналар куелды.

Судта

Балык Бистәсе районының 2 нче участкы халык суды Яңа Арыш авылында ирле-хатынлы Галимулла һәм Бикә Хәйруллиннарның эшен карады. Гаепләнүче Хәйруллин 1937—1939 нчы елларда Ленинградта эшләгән вактында үзенең хатыны Бикә Хәйруллинага бик күп мануфактура һәм төрле киемнәр җибәреп торган, ә хатыны бу әйберләрне спекуляция бәясеннән сатып килгән.

Халык суды Г. Хәйруллинны 5 елга иреккннән мәхрум итәргә һәм Бикә Хәйруллинаны 300 сум штраф түләргә хөкем итте.

Көндәлек вакыйгалар

ХУЛИГАН. Муратов урамындагы 2 нче йортта торучы Т. И. Лексин 4 нче маршрут трамвай вагонында барган вакытта тавыш куптарган. Ул пассажирларга бәйләнгән һәм Киселева дигән йөкле хатынның эченә аягы белән типкән. Киселева егылып, баласын төшергән. Аны авыр хәлдә больницага озатканнар. Лексин тотылып, җавапка тартылган.

Предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар игтибарына!

СССР Совнаркомының 1938 нче ел, 20 нче декабрьдә хезмәт кнәгәләре турында чыгарган 1320 нче номерлы карары нигезендә, барлык предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр хезмәт кнәгәләре өчен эшчеләрдән һәм хезмәткәрләрдән алынган акчалар сумасын Дәүләт Банкысына союзный бюджетка 12 нче раздел, 25 нче параграф буенча ай саен кертә барырга тиешләр.

Югалтылган хезмәт кнәгәләре өчен, югарыда күрсәтелгән карарның 12 нче статьясе тәртибендә алынган штрафлар союзный бюджетка 12 нче раздел, 2 нче параграф, 4 нче статья буенча кертелергә тиеш.

Һәрбер үткән квартал өчен, шул отчет кварталыннан соңгы айның 15 нче числосыннан да соңга калмыйча, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар шәһәр (район) финанс бүлекләренә түбәндәге форма буенча отчет бирергә тиешләр:

(Предприятиенең, оешманың яисә учреждениенең исме)

Хезмәт кнәгәләре бирү буенча алынган сумалар турында 19_____ елның______нче кварталы өчен отчет.

Тәртип № №	Хезмәт кнәгәләренең хәрәкәте	Сумасы	
		Сум	Тиен
1.	Квартал башлану вактына калган хезмәт кнәгәсе бланклары		
2.	Отчет кварталында алынган хезмәт кнәгәсе бланклары		
3.	Бигелгән һәм бозылган хезмәт кнәгәләре		
4.	Кварталның азагында калган хезмәт кнәгәсе бланклары		
5.	Югалтылган хезмәт кнәгәләре өчен алынган штрафлар сумасы		
6.	Союзный бюджет доходына кертү өчен Дәүләт Банкысына тапшырылган сума		

Предприятие, учреждение яисә оешма начальнигының һәм хезмәт кнәгәсе бирү өчен җаваплы кешенең имзалары.

Искәрмә: Беренче отчетта мәгълүмматлар 1939 нчы елның башыннан бирелергә тиеш.

Татнаркомфин.

233—1

Учреждениеләр һәм барлык гражданнар игтибарына

ВОЕНТОРГНЫҢ 1 НЧЕ МАГАЗИНЫНДА

(Бауман урамы, 42)

һәр төрле музыка кораллары, әдәбият, плакатлар, патефон пластинкалары, репродукторлар, кроватьлар бар.

Скоросшивательләр, обложкалар, бланклар учреждениеләргә хәзер акчасыз расчетлар буенча җибәрелә.

ВОЕНТОРГ.

291—1

Барлык дәүләт учреждениеләре, предприятиеләр һәм йорт идарәләре игтибарына белдерелә:

ШӘҺӘРНЕ ЧИСТАРТУ КОММУНАЛЬ ТРЕСТЫ

1940 нчы ел 1 нче февральдән

КАЗГОРТРАНС ТРЕСТЫНЫҢ АВТОПАРКЫ

дип яңадан исемләнде. Казан, Париж Коммунасы урамы, 18. Телефоннар: 27—00 һәм 39—48.

294—1

СССР Госпланының Счет Работниклары Хәзерләү управлениесе

ТАТАРСТАН УКЫТУ-КУРСЛАР КОМБИНАТЫ

ПРОИЗВОДСТВОДАН АЕРМЫЙЧА УКЫТЫП

счет работниклары хәзерләү һәм счет работникларының квалификацияләрен күтәрү буенча

КУРСЛАР АЧА:

1. Баш һәм өлкән бухгалтерларның һәм аларның урынбасарларының квалификацияләрен күтәрү группасы. Уку срогы 8 ай.

2. Бухгалтерларның квалификацияләрен күтәрү группасы. Уку срогы 6 ай.

3. Бухгалтерлар хәзерләү группасы. Уку срогы, каникул вактын исәпләмичә, 13 ай.

4. Хисапчылар хәзерләү группасы. Уку срогы 10 ай. Хисапчылар хәзерләү буенча татарлар өчен махсус группа оештырыла.

5. Уртадан түбән белемле (5—6 класс тәгәлләгән) кешеләр өчен хәзерлек группасы ачыла. Уку срогы 5 ай.

Барлык группаларда укулар кичке сәгатьләрдә, айга 15 тапкыр үткәрелә.

Гаризалар һәр көн кич 5 сәгаттән 10 га кадәр алына. Казан, Островский урамы, 22, 11 нче мәктәп.

251—2—2

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

Бүген, 16 нчы февральдә

МАСКАРАД

Талон 102.

17 һәм 18 нче февральдә

Бакчалар чәчәк ата

Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

Галиәсгар Камал исемендәге

Татар Дәүләт Академия театры

17 нче февральдә

КЫЮ КЫЗЛАР

Талон 117.

18 нче февральдә

көндез БАНКРОТ (талон 118)

кич КҮЗЛӘР (талон 119)

Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Бүген һәм һәр көн Москваның Ленин орденлы Дәүләт циркы артистларының ГАСТРОЛЕ

СТРАТОС—3

Номерлар орденлы артист БАСТ җитәкчелегендә башкарыла. Аэропланда үлем элмәкләре һәм башка күп номерлар.

РСФСР ның атказанган һәм орденлы артисты М. ЗОЛЛО гастрольләре дәвам итә.

Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

Совет кинематографиясенең XX еллыгы уңае белән,

„ЧАТКЫ" КИНО-ТЕАТРЫ

иң яхшы художестволы тавышсыз фильмнәр буенча

КИНОФЕСТИВАЛЬ

ҮТКӘРӘ.

Бүген, 16 нчы февральдә „Санкт-Петербургның бетүе" (1927 нче елда чыгарылган), 17 һәм 18 нче февральдә „Кастусь Калиновский" (1927 нче елда чыгарылган), 19 һәм 20 нче февральдә „Чыңгыз Хан нәселе" (1928 нче елда чыгарылган), 21 һәм 22 нче февральдә „Иуда" (1929 нчы елда чыгарылган) исемле тавышсыз фильмнәр күрсәтелә.

Сеансларда концерт оркестры уйный.

1—1

Курсантлар урнаштыру өчен 3—4 ай срок белән ашыгыч рәвештә

БҮЛМӘЛӘР ҺӘМ ПОЧМАК УРЫННАР КИРӘК

Толстой урамы, 41. Татнаркомлесның кадрлар бүлеге. 293—2—1

КУРСАНТЛАР УРНАШТЫРУ ӨЧЕН

3 ай срок белән

БҮЛМӘЛӘР КИРӘК

Түләү—килешү буенча. Тәкъдимнәр белән Казан Дәүләт Ветеринария институтының хуҗалык бүлегенә килергә. 270—2—1

КИРӘК:

Аптекалар үзәк складына ашыгыч рәвештә БАШ БУХГАЛТЕР. Хезмәт хакы килешү буенча. Профсоюз урамы, 26.

279—1

Юллар идарәсенең 257 нче участкысына тракторлар һәм юл машиналары буенча, шулай ук автохуҗалык буенча МЕХАНИКЛАР. Хезмәт хакы килешү буенча. Чехов урамы, 24. Телефон 40—46,

287—2—1

„Трансэнергокадр" ның Казан бүлегенә техорук булып эшләү өчен, АВТО ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА ИНЖЕНЕР һәм ИНСТРУКТОР БУЛЫП ЭШЛӘҮ ӨЧЕН ТЕХНИК - ЭЛЕКТРИКЛАР һәм ТЕПЛОТЕХНИКЛАР. Казан, Банк урамы, 15.

263—2—2

СОВЕТ КИНЕМАТОГРАФИЯСЕНЕҢ ЕГЕРМЕ ЕЛЛЫГЫ

1922 нче елның январенда иптәш Ленин Наркомпроска кино мәсьәләләре буенча махсус директива бирде. Авылларда һәм Көнчыгышта кино-театрлар оештыруга Ленин аеруча әһәмият бирде, чөнки анда „алар яңа нәрсәләр һәм шунлыктан анда безнең пропагандабыз аеруча уңышлы булачак" диде Ленин.

Совет кинематографиясен алга җибәрүгә иптәш Сталин гаять зур әһәмият бирде һәм бирә. 1924 нче елны партиянең XIII нче съездында ук иптәш Сталин „кино—массовый агитациянең гаять зур средствосы" диде һәм бу эшне партия кулына алу бурычын куйды.

Гражданнар сугышы елларында совет кинематографиясе үзен башлыча кинохроника һәм агитфильмнәр производствосы өлкәсендә күрсәтте. Художество дәрәҗәсе ягыннан артык югары булмауларына да карамастан, бу картиналар совет художество кинематографиясен хәзерләүдә күренекле роль уйнадылар.

1925—1926 нчы елларда экранда яш совет мастерларының беренче зур әсәрләре күренде. Режиссер С. Эйзенштейнның „Броненосец Потемкин" картинасы һәм режиссер В. Пудовкинның „Ана" (Горький повесте буенча) картинасы кебек фильмнәр совет кинематографиясен бөтен дөньяга таныттылар.

Бу чорда совет кинематографиясе илгә күп кенә әһәмиятле фильмнәр бирде. В. Пудовкинның „Санкт - Петербургның бетүе", „Чыңгыз Хан нәселе", А. Довженконың „Арсенал" һәм „Җир" фильмнәрен һәм күп кенә башкаларны күрсәтеп үтәргә мөмкин. Милли республикаларда да кинематография шактый уңышларга ирешә (Н. Шенгелайның „Элисо" сы һ. б.).

Гаять зур сәнгат көче—сүз белән, тавышлы картиналар белән—коралланган совет кинематографиясе иҗад үсешенең яңа чорына керә.

Яңа, совет кешесе, халык хуҗалыгын социалистик яңа баштан кору эпохасы герое образын күрсәтүне тагын да югарырак баскычка күтәргән күп кенә кино әсәрләре туа. Бу картиналар арасында Ф. Эрмлерның һәм С. Юткевичның „Каршылау" фильмы аеруча әһәмиятле роль уйнады.

„Максимның яшьлеге" (Г. Козинцев һәм Л. Трауберг тарафыннан эшләнгән) картинасы белән миллионнарча совет тамашачыларының мәхәббәтен һәм соклануын казанган большевик эшче экранга баса. Ф. Эрмлер коллективлашу турында беренче зур фильме—„Крестьяннар" дигән картинаны тудыра. М. Чиаурели Совет власте өчен грузин халкының көрәше турындагы зур картинаны—„Соңгы маскарад"ны бирә. Бу фильмнәрнең барсында да большевикның, масса җитәкчесенең, җәмгыятьне социалистик үзгәртеп кору өчен көрәшченең образын ачуга таба тагын да уңышлырак омтылышлар ясала.

„Чапаев" (режиссерлары Г. һәм С. Васильевлар) фильмен тудыру совет кино сәнгатенең гаять зур җиңүе булды. Чапаевның легендар образы, гаять зур художестволы идея образы кыска вакыт эчендә Советлар иле халыклары массасының сөеклеле образы булып әверелде.

Халык тарафыннан сөелгән Чапаев, Фурманов, Максим образларыннан соң партиясез большевик—профессор Полежаев (режиссер Хейфиц һәм Зархиның „Балтика депутаты"), матрос Артем Балашов (Е. Дзиганның „Без Кронштадтан" дигән картинасында) образлары тудырыла.

Кино тирәсендә талантлы актерларның зур отряды тупланды. Вакытсыз арабыздан киткән мастер Б. Щукинның таланты В. И. Ленинның аның тарафыннан тудырылган образы белән совет кинысында эз калдырды һәм ул совет халкының хәтерендә озак яшәр. Н. Черкасов (профессор Полежаев һәм Александр Невский рольләрендә), Б. Чирков (Максим ролендә), Н. Боголюбов („Бөек гражданин" да Шахов ролендә), Симонов, М. Жаров, Н. Охлопков, М. Штраух, Л. Орлова һәм башкалар совет тамашачылары каршында гаять зур ихтирам казандылар. Аларның кино өлкәсендәге эшләре хөкүмәтнең югары бүләкләре белән искә алынды.

Художестволы кино-картиналар эшләү турында һәм СССР Совнаркомы янында кинематография эшләре буенча Комитет төзү турында хөкүмәтнең 1938 нче ел 23 нче март карары совет кинематографиясе тарихында әһәмиятле этап булды.

Партия һәм хөкүмәт совет кино работниклары алдына хезмәт ияләре массасын коммунизм рухында тәрбияләүче, социалистик төзелеш эшенә, Ленин—Сталин партиясе эшенә чын күңелдән бирелгәнлек хисләре тудыручы фильмнәр бирү бурычын куйдылар.

Иптәш Сталин массаны коммунизм идеяләре рухында тәрбияләү өчен кинодан файдалану кирәклеген аеруча күрсәтте.

Турыдан-туры иптәш Сталин күрсәтмәсе буенча художестволы кинематография алдына экранда СССР халыкларының героик тарихын күрсәтү бурычы да куелды. Коммунистлар партиясенең күренекле эшлеклеләре, гүзәл большевиклар турында биографик фильмнәр тудыру турындагы задание аеруча мактаулы һәм җаваплы.

Шушы иҗади бурычларны тормышка ашырып, совет кино сәнгате шактый зур җиңүләргә ирешә. „Ленин Октябрьдә" (режиссеры М. Ромм). „Мылтыклы кеше" (реж. С. Юткевич), „Бөек таң" (реж. М. Чиаурели), „Ленин 1918 нче елда" (реж. М. Ромм), „Выборг ягы" (реж. Г. Козинцев һәм Л. Трауберг) фильмнәрендә Лениннең һәм Сталинның бөек образлары беренче тапкыр буларак гәүдәләнделәр.

Соңгы еллар совет кино сәнгате тарихи һәм тарихи-революцион тематиканы да уңышлы үзләштерүен күрсәтте. 1938 һәм 1939 нчы еллар совет экранына „Петр Беренче" нең икенче сериясе (реж. В. Петров), „Александр Невский" (реж. С. Эйзенштейн), „Минин һәм Пожарский" (реж. В. Пудовкин), „Степан Разин" (реж. О. Преображенская һәм И. Правов) кебек әсәрләр бирделәр.

Хәзерге заман совет темаларын чагылдыру бурычы әле начаррак үтәлә. Үзләренең идея һәм художество дәрәҗәләре буенча күренекле берничә әсәрне генә күрсәтеп үтәргә мөмкин. „Бөек гражданин" (реж. Ф. Эрмлер) фильменең икенче сериясе һәм „Күтәрелгән чирәм" (реж. Ю. Райзман), „Хөкүмәт члены" (реж. И. Хейфиц һәм А. Зархи), „Укытучы" (реж. С. Герасимов) картиналары турында искә алып үтәргә кирәк. Совет киносының бурычы—тамашачыга социализм төзүчеләрнең тормышлары турында сөйли торган картиналарны шактый күбрәк бирү.

Оборона тематикасы, героик Кызыл Армиябезнең тормышы экранда әле һаман да җитәрлек дәрәҗәдә чагылдырылмый. Кино комедияләр дә бик аз.

Гомумән, Совет кинематографиясе үсешенең егерме еллыгы идея һәм художество ягыннан туктаусыз үсешне күрсәтә. Совет кино сәнгате, кино работникларының бөтен коллективы бөек Сталин эпохасына лаеклы, ачык художестволы әсәрләр тудыру өчен киләчәктә дә көрәшерләр.

И. Большаков.

СССР Совнаркомы янындагы кинематография эшләре комитеты председателе.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Яңа фильм ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„УНИОН" 11, 1-20, 3-40, 6, 8-20, 10-30 да.	ДИҢГЕЗ ПОСТЫ „СЕДОВЧЫ ГЕРОЙЛАРГА ДАН" һәм „СОВЕТ СӘНГАТЫ" киножурналлары күрсәтелә.
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	КОМСОМОЛЬСК
„Колхозник" 4, 6, 8 һәм 10 да.	Инженер Кочинның ялгышуы
„ЧАТКЫ" 6, 8 һәм 10 да.	Санкт-Петербургның бетүе
„ПИОНЕР" 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 5-30, 7-10, 8-50, 10-30 да.	Көндезге һәм кичке сеансларда ПАТРИОТ Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ" 4, 6, 8, 10 да.	СОҢГЫ ТӨН
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	УНБЕР БАШКАЛА

Җаваплы редактор

Һ. АБДРАХМАНОВ.

Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.